ТАРТУ КӨЧЕ

Кемдер кушканга түгел, йөрәк әйткәнне тыңлап, авылда калган яшьләрне барладык

> 16

ИСКЕЛЕК КАЛДЫГЫ

Казан кебек зур шәһәрләрдә тәүлегенә 10 тоннага якын чүпрәк-чапраклы чүпкә ташлыйлар

> 17

ЗӨФӘР МӨХӘММӘТШИН:

Өч шәхес: Сөембикә, Тукай, Җәлилгә кагылырга ярамый

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 57 (29024) | Җомга | 21 апрель | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

16.mchs.gov.ru

СУ БИРЕГЕЗ!

ИРТӘ ЯЗ ЯНГЫННАР ДА АЛЫП КИЛДЕ

Республиканың 13 авылында янгын чыкса, сүндерергә су да юк! Урамнары белән янып бетәргә мөмкиннәр. Инде бу көннәрдә халык теленнән төшмәгән Актаныш районындагы хәлләрдән дә сабак алырлык. Буаз Күлдә ун корылма янган, Пучы авылындагы өмәдә зиратка ут кабып, бер йорт көлгә әйләнгән... Мондый хәлләрне күп санарга була. Менделеевск районында зиратка таба үрмәләгән янгын, Мамадыш районының Новый Закамский бистәсендә 15 гектар коры үлән янып, аның бер йортка күчүе...

> 6

БӘЙРӘМ МӨБАРӘК БУЛСЫН!



Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Ураза бәйрәме уңаеннан ТӘБРИКЛӘВЕ

Кадерле татарстанлылар!
Хөрмәтле ватандашлар!

Сезне рамазан ае тәмамлану һәм Гайдел-фитр – Ураза гаете уңаеннан чын йөрәктән котлыйм.

Бу изге айда миллионлаган мөселман күңелен рухи пакьләнүгә, миһербанлы гамәлләр кылуга юнәлтте.

Һәрвакыттагыча хәзерге көннәрдә дә республиканың мөселман өммәте вәкилләре җәмгыятебезнең әхлакый нигезләрен, милләтләр һәм диннәр арасындагы тынычлыкны һәм татулыкны ныгытуга зур өлеш кертә, дини-мәгърифәти һәм хәйрия эшчәнлеге алып бара.

Бу катлаулы заманда чыганагы Коръән Кәрим булган традицион идеалларга һәм рухи хәзинәләргә тугрылык саклау мөселманнар өчен аеруча мөһим. Кешеләрнең иманын, әхлагын, гаиләсе өчен җаваплылык хисен кочәйтә барып, без илебезнең киләчәген төзибез. Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында болар аеруча зур әһәмияткә ия.

Күптән түгел генә республика һәм Россия мөселманнары истәлекле тарихи вакыйга – Идел буе Болгар дәүләтенең 1100 еллыгын дәүләт дәрәҗәсендә билгеләп үтте. Безнең уртак тырышлык нәтиҗәсендә юбилей елының күпсанлы башлангычлары һәм проектлары лаеклы төстә гамәлгә ашар дип ышанам.

Ураза бәйрәме киләчәккә якты өметләрне, ышаныч һәм рухи күтәренкелекне тагын да көчәйтсен! Һәммәгезгә бәхет, тынычлык, игелек һәм иминлек телим!

Реклама 16+

Сөенечле хәбәр!

2023 елның 10–27 апрель көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны — **Ташламалы бәя** **444 сум 54 тиен**, гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — **Ташламалы бәя** **1051 сум 80 тиен**, гадәти бәясе – ~~1227 сум 30 тиен~~

Ният һәм эш

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов «Интерфакс» агентлыгына ислам илләре белән мөнәсәбәтләр һәм ике арада хезмәттәшлек юнәлешләре турында сөйләде. Төп фикерләрне тәкъдим итәбез.

Казанда узачак «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» турында

«KazanForum»га ил күләмендә тиң юк. Әлеге чара федераль статуска ия булган өчен Россия Президенты Владимир Путинга рәхмәт. Форумның төп максаты илебезнең мөселман илләре белән элемтәләрен тагын да үстерүдән гыйбарәт. Әлеге җыенны мин 2014 елдан бирле җитәкчелек иткән «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме алып барган зур эшнең бер өлеше итеп кабул итәбез. Чыннан да, «KazanForum» яңа һәм әһәмияте ягыннан көн кадагында торган эш юнәлешләрен ачарга ярдәм итә. Мәсәлән, соңгы елларда үсеш алган хәләл индустрияне генә алыйк. Бу мәсьәләдә өйрәнәсе һәм эшлисе эшләр байтак әле. Партнерлык банкингы буенча федераль үзәк белән дә, ислам илләрендәге хезмәттәшләребез белән дә актив хезмәттәшлек итәбез. Форумда БДБ илләре, Якын Көнчыгыш, Көньяк-Көнчыгыш Азия, Африка илләреннән кунаклар һәм спикерлар катнашачак. Җыенда ил җитәкчелеген, федераль хакимият органнары вәкилләрен, Россия төбәкләре башлыкларын, Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илчеләрен дә көтәбез.

Россиянең ислам дөньясы илләре белән мөнәсәбәтләрендә Татарстанның урыны турында

Ислам дөньясы белән хезмәттәшлек итү һәрвакытта да республиканың тышкы икътисадый һәм халыкара эшчәнлегендә төп элементларның берсе булып торды. Хәзерге шартларда бу аеруча да зур әһәмият алды. Төп юнәлешләр – БДБ вәкилләре булган тугандаш илләребез, гарәп дөньясы, Иран, Төркия, Көньяк-Көнчыгыш Азия дәүләтләре. Барыннан да бигрәк, сәүдә-икътисадый хезмәттәшлекне үстерергә телибез. Экспортка йөз тоткан төбәк буларак, Татарстан сәнәгать һәм авыл хуҗалыгына бәйле күпсанлы продукция тәкъдим итәргә әзер. Ислам дөньясы илләре белән товар әйләнешенең яртысы диярлек БДБ илләренә туры килә. Шунысы да бар: соңгы бер елда ерак чит илләр белән сәүдә күләме якынча ике тапкыр арткан. Барыннан да бигрәк, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Төркия һәм Марокко белән ике арадагы товар әйләнеше үсте. Инвестицион хезмәттәшлеккә дә аерым игътибар бирәбез. Ике арада мондый проектлар әлегә күп түгел, билгеле. Әмма бу юнәлештә зур эш алып барыла.

Җанисәп нәтиҗәләре, татарлар саны кимү турында

Әйе, җәмгыятьтә, бигрәк тә милли җәмәгатьчелектә халык санын алуга бәйле бәхәсләр бара: җанисәпнең методологиясе, аны цифрлаштыруга бәйле кимчелекләр турында тарткалашалар; үз милләтен күрсәтмәгән гражданнарның саныйлар (халык саны күпмегә кимегән һәм бер татарларда гына түгел); үз милләтен күрсәтүдән баш тарткан 16 миллионнан артык Россия гражданы арасында руслар, татарлар һәм башка халык вәкилләрен эзлиләр. Әлеге фикер алышулар һәм, бәлки, ачыкланачак кимчелекләр алдагы җанисәпне үткәрү барышында файдалы булачак. Татарстанда татарлар саны арткан. Әмма илнең башка төбәкләрендә кимегән. Бу нәрсәгә бәйле? Моңа төгәен бәяне галимнәр һәм тармак белгечләре генә бирә алачак. Белүемчә, мондый анализ алып барыла. Җанисәпнең төп нәтиҗәсе: үзләрен татарлар дип күрсәтүчеләр алга таба да үз телен, мәдәниятен саклап калсын һәм киләчәк буыннарга тапшыра алсын өчен, без хәлдән килгәннең барысын да эшләргә тиеш.

Ту-214не җитештерү турында

Чит ил компанияләренең ил базарыннан китүе үзебезнең машина төзүчеләр, шул исәптән авиатөзелеш өлкәсендә дә яңа мөмкинлекләр ача. Әйтергә кирәк, Казан авиация заводы беркайчан да Ту-214не җитештерүдән туктамады. Предприятиедә серияле җитештерү җайга салынган, эшнең тулы бер циклы гамәлдә. Сүз җитештерү күләмен арттыру турында бара. Татарстанның «ЮВТ Аэро» авиакомпаниясе 4 машина сатып алырга җыена. «Аэрофлот»ка 11 очкыч җитештерүгә бәйле килешү төзелгән. Алга таба җитештерү куәтен тагын да үстереп, елына 10 очкыч җыя башлау, ә киләчәктә бу санны 20гә кадәр җиткерү нияте бар. Дәүләт һәм коммерцияле заказларны тәэмин итү өчен, берьюлы берничә партия очкыч җитештереләчәк.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

Рөстәм Миңнеханов Алабуга районында язгы кыр эшләре барышы белән танышты. Быел бигредә чәчү мәйданы 38,8 мең гектарга җиткән. Кырларда 65 агрегат эшли. Район башлыгы Рөстәм Нуриев мөгезле эре терлек санын 20 процентка арттыруларын, ә бер тәүлектә савылган сөт күләмен, 2020 ел белән чагыштырганда 3 тапкыр арттырып, 93,6 тоннага җиткерүләрен әйтте. «Элек сезне тәнкыйтьли идек, хәзер исә төп күрсәткечләр – терлек саны, сөт һәм хезмәт хакы күләме буенча үсеш барлыгын күрәбез. Яңа фермалар ачыла. Гомумән алганда, районда авыл хуҗалыгына зур игътибар бирелә», – диде Татарстан Рәисе.

***

Рөстәм Миңнеханов Чулман елгасы аша салынучы зур күпер төзелешен барып карады. Ул М7 «Волга» федераль трассасында Чаллы һәм Түбән Каманы әйләнеп узу юлында иң зур объектлардан берсе санала. Алабуга районының Котловка авылы янында башланып, елга аша Түбән Кама районына чыгучы күпернең озынлыгы 1300 метр тәшкил итә. Ул Казаннан Түбән Кама һәм Зәй ягына баручыларның юлын кыскартачак.

***

Рөстәм Миңнеханов Мамадыш районында да язгы кыр эшләре барышы белән кызыксынды. Район башлыгы Анатолий Иванов әйтүенчә, басуларда эш тулы куәтенә бара, 130 берәмлек техника эшли, чәчүлек мәйданы 78 мең гектар тәшкил итә. Татарстан Рәисе «Продпрограмма» агросәнәгать комплексын карады. Яңа корпусларда 4307 баш эре мөгезле терлек асрала, көн саен 115 тонна сөт савыла. Республика башлыгы «Азбука сыра» заводында да булды. Узган ел биредә 129 мең тонна сөт эшкәрткәннәр. Көн саен 70 тоннага кадәр продукция, шул исәптән 45 тоннага якын сыр җитештерәләр.

tatarstan.ru



Рөстәм Миңнеханов Мәскәүдәге Рамазан чатырында узган Татарстан кичәсендә катнашты. Ифтар мәҗлесенә Россия Мөфтиләр шурасы рәисе Равил Гайнетдин, Мәскәү өлкәсе хөкүмәте башлыгы Илдар Габдрахманов, РФ Президентының эчке сәясәт буенча идарәсе дини оешмалар белән хезмәттәшлек итү департаменты башлыгы Евгений Еремин, Дәүләт Думасына Татарстаннан сайланган депутатлар белән бергә Төркия, Сүрия, Бангладеш, Малайзия, Үзбәкстан, Әфганстан, Мавритания илчеләре һәм тагын 30лап илнең дипломатия вәкилләре катнашты. Татарстан Рәисе аларның барысын да республиканы килеп күрергә чакырды.

ЙОРТ КЫНА АЗ

Гаилә ипотекасын тагын да гадиләштерү, мәктәп һәм балалар бакчалары төзелешенә федераль үзәктән бирелгән акчаны арттыру. Мәскәүдә Төзелеш министрлыгы һәм илнең төбәкләр үсеше буенча Хөкүмәт комиссиясе президиумының уртак утырышында әнә шул мәсьәләләр күтәрелде. Аның эшендә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Былтыр төзелеш тармагында ирешкән уңышлар турында Россия төзелеш һәм ТКХ министры Ирек Фәйзуллин сөйләде. РФ Дәүләт Советының Төзелеш, ТКХ һәм шәһәр мохите буенча комиссиясе җитәкчесе буларак, Рөстәм Миңнеханов ил төбәкләре исеменнән тармакка даими ярдәм күрсәтүләре өчен, Россия Президентына, ил Хөкүмәтенә һәм Төзелеш министрлыгына рәхмәт белдерде.

Аның әйтүенчә, республикада былтыр рекордлы күләмдә – 3 миллион квадрат метрдан артык торак кулланышка тапшырылган. Алга таба зур инфраструктура проектларын алдан финанслау да торак төзелеше үсешенә этәргеч бирәчәк, диде ул.

– Илкүләм проектлар, коммуналь инфраструктураны яңарту программасы ярдәмендә халыкның тормыш сыйфаты яхшыра. Татарстанда гамәлдә булган 44 республика программасы да шуңа юнәлдерелгән. Былтыр Татарстанда 4 меңнән артык социаль һәм коммуналь инфраструктура объектлары төзелде һәм төзекләндерелде, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Торак базарында сорау кимүен дә билгеләп үтте ул. Вазгыятьне яхшырту өчен гаилә ипотекасының шартларын «йомшартырга» – кредит күләмен хәзерге 6 миллион сумнан 10 миллион сумга кадәр җиткерергә, беренчел кертемне – 10, ә күпбалалы гаиләләргә 5 процентка кадәр киметергә, 4,5 процент күләмендә кредит ставкасын кире кайтаруны карап тикшерергә кирәклеген искәртте.

Рәис сүзләренә караганда, торак төзелеше социаль инфраструктура белән бергә үсәргә тиеш. Мәсәлән, төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре буенча, 3 миллион квадрат метр торакны кулланышка тапшыру өчен 48 балалар бакчасы, 18 мәктәп, 9 шифаханә төзергә һәм 75 чакрым юл салырга кирәк. Федераль үзәктән бүлеп бирелгән акча җитмәү сәбәпле, төбәкләр бу эшне үз хисабына башкарырга мәҗбүр. Узган ел Татарстанда гына да әлеге җәһәттән 60 миллиард сум, ягъни үз керемнәребезнең 14 проценты күләмендә акча тотылган.

– Бу гына да аз әле. Таләп ителгән 18 мәктәп урынына 9 уку йорты төзедек, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Социаль объектлар һәм инфраструктура төзелеше өчен федераль үзәктән финанслауны арттыру мәсьәләсен яңадан тикшерүне сорыйбыз. Эшнең бәясенә нормативлар үзгәрү дә тәэсир итте. Әйтик, моннан 30 ел элек 1,5 мең урынга исәпләнгән мәктәпнең мәйданы 15 мең квадрат метр булса, хәзер ул – 27,6 мең квадрат метр.

Эшнең мәйданы арткач, бәясе дә кыйммәтләнгән, билгеле. 2019 елда мондый мәктәп салу 1,5 миллиард сумга төшсә, быелтыр 60 процентка артып, 2,4 миллиард сумга җиткән. Утырышта акчаны янга калдыру өчен нормативларны киметергә дә тәкъдим иттеләр.

Торак-коммуналь хуҗалыкның торышы һәм үсеше дә – катлаулы мәсьәләләрнең берсе. Бу уңайдан, Рөстәм Миңнеханов РФ Дәүләт Советы Президиумы утырышы йомгаклары буенча коммуналь инфраструктураны яңартуга бәйле программаны гамәлгә кертүләре турында искә төшерде. Гомумән, торак-коммуналь хуҗалык тармагында даими контроль кирәк. Татарстанда коммуналь түләүләрне җыю күрсәткече 99 процент тәшкил итә.

– Бу – 2018 елда республикада Бердәм исәп-хисап үзәкләре оештыруның уңай нәтиҗәсе. Оешмалар әлеге үзәк белән килешү төзеде. Без бу уңайдан тәҗрибә уртаклашырга әзер. Барлык идарәче һәм ресурсларны саклау оешмаларына түләүләрне Бердәм исәп-хисап үзәге аша үткәрүне нормативлар нигезендә беркетергә тәкъдим итәм. Бу үтә күренмәлелекне тәэмин итәргә булышачак, – диде Рөстәм Миңнеханов.

СЫНАЛЫР ЧАКЛАР

Парламентның кырык өченче утырышында иң күп вакытны Хөкүмәт рәисе Алексей Песошинның чыгышы алды. Әмма берәүне дә ялыктырмады. Чөнки төрле чикләүләр заманында башкарма хакимиятнең ничек эшләвен яки нәрсәне эшләп җиткермәвен Хөкүмәт рәисенең үзеннән ишетәсе килә иде. Әлбәттә, үз эшенә хисап тотканда һәр җитәкче күбрәк уңышлар турында сөйләргә омтыла инде ул.

tatarstan.ru

Алексей Валерьевич та дөнья глобаль үзгәрешләр кичергән чорда Татарстанда тотрыклылык саклануын, алай гына да түгел, республикабызның үсешкә юл тотуын әйтеп шатландырды. Дәлилләр, саннар китереп чыгыш ясады ул.

Узган ел 3 трлн 865 млрд сумлык тулай төбәк продукциясе җитештергәнбез. Моңа икътисад үсешенең 106 процент тәшкил итүен дә өстәргә кирәк. Кайсы тармакны гына алма, үсеш күзәтәсең. Мәсәлән, торак төзелешен генә алсак та, 3 млн кв. метр торак мәйданы файдалануга тапшырылып, бер кешегә торак мәйданы 29,2 кв. метрга җиткән. Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләме 126 процентка арткан. Хөкүмәт рәисе бездә уртача гомер озынлыгының 75 яшькә җитә язуын әйтеп тә шатландырды. Димәк, мин тиздән «уртача»ны узып, озын гомерлеләр ягына таба атлый башлаячакмын. Тормыш начар булса, озак яшәү турында уйлап та булмый ул, дип куанам.

Әлбәттә, сөенечләр белән бергә көенечләребез дә шактый. Мәсәлән, узган ел республикага читтән тауар кертү 20 процентка кимегән. Димәк, чит илнекеләргә баш бирмәслек тауарларны үзебез җитештерергә тиеш булабыз. Баксаң, илдә үзебезнең чәчү орлыклары да җитенкерәми икән. Бу инде азык-төлек иминлегенә дә куркыныч янауны аңлата. Бездә җитештерү җиһазларына да кытлык бар. Ә яңа технологияләр булдыру өчен, яңадан-яңа фәнни ачышлар кирәк. Бездә уйлап табулар да бераз кимегән.

«Акыллы баш»ларның илне ташлап китүләре белән кызыксынганым бар. 2012 елдан башлап читтә яшәү һәм эшләүне хуп күргән галимнәр саны биш мәртәбә арткан икән. Бүген алар 70 мең чамасы ди. Галимнәр саны Татарстанда да кимегән, әмма алай ук куркыныч түгел бугай. 2017 елда бездә 362 фән докторы булса, бүген 310га калган дигән мәгълүмат күзгә чалынган иде. Галимнәр булмагач, уйлап табулар да кими инде ул.

Утырышта депутат Николай Атласов чүп реформасының ни өчен тормышка ашып бетә алмавы белән кызыксынган иде. Хөкүмәт рәисе реформаның без теләгән тизлектә бармавын яшермәде. Сәбәбе нидә? Баксаң, чүп эшкәртү, чүп яндыру заводы төзелеше тоткарлана, шуның өстенә заводка җиһазлар кайтару да баш авыртуына әйләнгән икән. Япония кебек безгә каршы илләрнең безне заман технологиясе белән тәэмин итәселәре килми, бүген бөтен өмет Кытайда булып чыга инде.

Алексей Валерьевич яшәешебезнең һәр өлкәсенә тукталып, шактый ук тәфсилле чыгыш ясаса да, аңа «бу тармакны телгә алмадыгыз, теге өлкәгә кагылмадыгыз...» диючеләр шактый булды. Хөкүмәт рәисе һәр депутат соравына җавап бирде үзе. Тик депутат, КПРФ фракциясе җитәкчесе Хафиз Миргалимовның дәгъвалары шактый җыелган иде. «Сүз дә юк, Рөстәм Миңнеханов командасы бик әйбәт эшләде. Ә нәрсә эшләп җиткермәдек?» – диде дә кимчелекләрне санап китте. «Бездә айлык уртача хезмәт хакы 52 мең сум икән, бу хәтле акчаны кемнәр ала? Бездә фәкыйрьләр күпме? Авыл хуҗалыгы продукциясен күп җитештерү белән мактандык, ә нигә ризык бәяләре артты? Мәсәлән, сөтнең үзкыйммәте бик югары түгел, ә нигә ул кибеткә ике-өч тапкыр артык бәя белән чыгарыла? 35 квадрат метрлы фатир өчен түләү аена җиде-сигез меңгә җитте, ә аз керемлеләр башка ихтыяҗларына каян акча җиткерсен?! Татарстанның 24 районында эчәр суның сыйфаты тиешле таләпләргә туры килми. Хакимият халыкка якынрак булырга тиеш...» Хафиз иптәшнең төп дәгъвалары әнә шулардан гыйбарәт иде.

Хөкүмәт рәисен тыңлаганда шуны уйлап утырдым әле: дөньяның, ачуым бер килмәгәе, асты өскә килгәндә дә, безнең халык матур киләчәккә өметен өзми. Бер уйлаганда, махсус хәрби операция ил, халык тормышына бик тискәре йогынты ясарга тиеш иде кебек. Ә без авырлыкларны артык сизмибез дә кебек. Яшь гомерләрнең әрәм булуы турында кайгырмаганда, диюем. Кибетләрдә ни телисең – шул бар, хезмәт хакы, пенсия килеп тора. Әле тыныч вакытларда да, Ельцин хакимлек иткән чорны әйтәм, кешенең берничә ай, яртышар, берәр ел хезмәт хакы ала алмавын искә төшерәм дә гаҗәпләнеп куям. Нинди генә авырлык килсә дә, коелып төшми безнең халык! Зарланып утырасы урынга, кыенлыктан чыгу юлларын эзли. Мин моны аңлыйм да кебек. Безгә бер кайгысыз, тыныч кына яшәргә димәгән. Сынау артыннан сынау килеп торганга, чарланып, каешланып беткән, ахрысы, Россия халкы.

Алексей Песошин алда яңа кыенлыклар килеп чыгарга мөмкинлеген дә яшермәде. Республика җитәкчелеге эшенә килсәк, махсус хәрби операция башлануга ук, бездә, Россия Президенты кушуы буенча, тотрыклы үсеш тәэмин итү максаты белән республика штабы оешты, махсус чаралар планы төзелде һәм алар үз вакытында тормышка аша килде.

Җәмгыятьтә киеренкелек тумасын өчен, гражданлык институтлары да яхшы эшләделәр. Мин халыкка якын торган Иҗтимагый палатаны күз алдында тотам. Аның җитәкчесе Зилә Вәлиева әйтүенчә, нинди генә катлаулы заман булмасын, узган 2022 ел Татарстан халыкларының бердәмлеген, милләтара, динара татулыкны тагын да ныгытты. Утырышта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары турында» Законга үзгәрешләр кертүгә кагылышлы закон проекты каралды. Татарстан юстиция министры Рөстәм Заһидуллин әйтүенчә, проект безнең законнарны «Россия субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары» дигән федераль закон белән тәңгәлләштерүне күз алдында тота. Аерым алганда, элек бездә башкарма хакимият системасын булдыру парламент вәкаләтендә булса, хәзер бу вәкаләт Татарстан Республикасы Рәисенә тапшырылачак. Закон проектында дәүләт хакимияте башкарма органнарын оештыруның хокукый нигезләре һәм эшчәнлеге турында да язылган. Әлеге үзгәрешләр хакимият вертикален тагын да ныгытуны күз алдында тота кебек. Каш ясыйбыз дип, күз генә чыгармыйк инде. Хәер, өстәгеләр яхшырак беләдер.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ УКАЗЫ

«Сабан туе» татар халык бәйрәмен уздыру турында

2023 елда «Сабан туе» татар халык бәйрәмен үткәрү максатында һәм «Татарстан Республикасының бәйрәм көннәре һәм истәлекле даталары турында» 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып, «Сабан туе» татар халык бәйрәмен түбәндәге срокларда уздырырга:

Татарстан Республикасы авыл торак пунктларында, район үзәкләрендә (шул исәптән республика әһәмиятендәге шәһәрләрдә) – 2023 елның 10–11 июнендә;

Чаллы шәһәрендә – 2023 елның 17 июнендә;

Татарстан Республикасы башкаласы Казан шәһәрендә – 2023 елның 24 июнендә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җирле үзидарә органнары белән берлектә бәйрәм чараларын күрсәтелгән срокларда уздыруны оештыруны тәэмин итәргә.

3. Җирле үзидарә органнарына, җәмәгать берләшмәләренә, предприятиеләргә, оешмаларга «Сабан туе» татар халык бәйрәмен әлеге Указда билгеләнгән срокларда оештыруда һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2023 ел, 19 апрель, № 247

Җирле үзидарә көне белән!

Хөрмәтле муниципаль берәмлекләр башлыклары, депутатлар, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре һәм ветераннар!

Сезне һөнәри бәйрәмегез – Җирле үзидарә көне белән котлыйм!

Соңгы елларда Татарстанда җирле үзидарә хакимият институты буларак формалашу һәм ныгу юлын узды һәм бүген дә камилләшүен дәвам итә.

Җирле үзидарәне үстерү, аның нәтиҗәлелеген, ресурс һәм кадрлар мөмкинлекләрен арттыру – эшебезнең төп юнәлешләре. Бүген республиканың һәр муниципалитетында югары сыйфатлы эш алып барыла – территорияләрне төзекләндерү, торак-коммуналь хуҗалыкны, социаль һәм транспорт инфраструктураны ныгыту һәм башкалар.

Халыкка иң якын дәрәҗәдәге иҗтимагый хакимият буларак, җирле үзидарәнең төп бурычларының берсе – халык белән элемтәдә булу, кеше мәнфәгатьләрендә эшләү. Бу ил Президенты игълан иткән махсус хәрби операция шартларында аеруча әһәмияткә ия, эшебездә яңа бурычлар һәм юнәлешләр куя. Татарстан муниципаль берләшмәсе гуманитар ярдәм җыю буенча күпсанлы акцияләрдә актив катнаша, хәрби операциядә катнашучыларга, аларның гаиләләренә һәрьяклап ярдәм күрсәтә.

Хөрмәтле хезмәттәшләр, сезгә һөнәри осталык һәм тугрылык өчен рәхмәт белдерәм. Көн дә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итәсез, бу кешеләрнең проблемаларына сакчыл мөнәсәбәт, Ватанга һәм кече ватаныгызга мәхәббәт таләп итә.

Муниципаль берәмлекләрнең барлыкка килү вакытында эшләгән һәм республикабыз үсешенә лаеклы өлеш керткән җирле үзидарә органнары ветераннарына аерым рәхмәт сүзләрен җиткерәм.

Бу бәйрәм көнендә сезгә нык сәламәтлек, бәхет, җаваплы эштә профессиональ уңышлар, туган Татарстан файдасына яңа казанышлар телим!

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе рәисе
Ә.С. ГОБӘЙДУЛЛИН

МИЛЛӘТ АНАЛАРЫ

Татарстан, Россия һәм чит илләрдән 500дән артык хатын-кыз башкалага тел, милләт, мәдәният, тәрбия һәм башка мәсьәләләрне уртага салып сөйләшергә киләчәк.

24–26 апрель көннәрендә Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты «Ак калфак» татар хатын-кызлары оешмасы белән берлектә III Бөтендөнья татар хатын-кызлары съездын уздыра.

Әлеге съездга делегат буларак Россиянең 53 төбәгеннән, 15 ерак һәм якын чит илләрдән килерләр дип көтелә. Әйтик, Белоруссия, Болгария, Кытай, Литва, АКШ, Польша, Төркия һәм башка илләрдән дә кунаклар булачак.

Быел, мәдәният-сәнгать, традицияләргә игътибар бирү белән берррәттән, милли мәгариф, тәрбия мәсьәләсенә дә басым ясалачак. Съезд көннәрендә хатын-кызларны бай программа көтә. Алар шәхси мәктәпләргә барачак, КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты эшчәнлеге белән дә танышачак, күргәзмә-ярминкәдә дә катнашачак. Делегатлар белән өч төрле юнәлештә фикер алышу алып барылачак.

24 апрельдә съездның пленар утырышы узачак.

Әйтеп кенә бактым

Урысча әйткәндә...

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Беркөнне дуслардан, танышлардан нинди телдә уйлауларын сорашып чыктым. Кызык хәл: күбебезнең урысчасы да әллә ни түгел, хәтта такы-токырак диярге була. Әмма еш кына урысча җөмлә төзибез дә, аннан шуны татарчага тәрҗемә итәбез икән. Бер телдә уйлау, икенче телдә сөйләү һәм язу галәмәтләрен үземдә дә күптән сизә идем. Юкса татар авылында туган, татар мәктәбендә, алай гына да түгел, Казан университетында да ана телендә белем алган кеше бит мин һәм гомер буе татар мохитендә яшим. Каян килгән миңа ике телдә фикер йөртү?! Ике яки берничә телне бертигез дәрәҗәдә камил белгән кешеләр бар инде ул. Мәсәлән, танылган язучы-публицист Рафаэль Мостафин шундый иде, урыны оҗмахта булсын. Урысча да, татарча да иркен сөйләште һәм иркен язды ул. Арагызда тагын шундый кем бар, кулыгызны күтәрегез! Бик юктыр шул, короче говоря, ике телне дә су кебек эчү бик ансат түгел. Примерга, Дәүсовет утырышларында чыгыш ясаучы кайбер депутатларны гына алыйк. Кайберләрен, урысча сөйләсәләр дә, татарчага күчсәләр дә, урыны-урыны белән аңлавы кыен. Әле хезмәттәшем Фәния Әхмәтҗанова әйтеп торды, моның бер танышы икетеллелеккә шулхәтле тирән кереп киткән, бер генә телдә, гомумән, сөйләшә алмый башлаган. Җөмләсенең яртысы урысча, яртысы татарча икән. Урысча әйткәндә, полная каша инде.

Күп тел белү, әлбәттә, зур байлык. Тик миңа танылган татар шагыйрьләре, язучылары, журналистлары ни өчен кайчак «ике каен» арасында буталып калгалыйлар?

Үтә дә милли җанлы бер дустым, танылган шагыйрь: «Кайчак үзем дә шаккатам. Язып утырганда, кирәкле татар сүзе таба алмый аптырап калган чаклар була. Юкса телебез гаҗәп бай бит, әмма үз фикеремне төгәл җиткерердәй сүз таба алмыйм да урысчага күчеп алам», – дигән иде.

Бер кызык хәл искә төште әле: 2010 елда, Тукай эзләре буйлап, Казахстанга һәм Кытайга иҗади сәфәргә чыккан идек. Кытайда яшәүче татарларның урысча бер генә сүз дә кыстырмыйча сөйләүләренә шаккаткан идем мин. Как-так, мин әйтәм, без автоматически булса да берәр урыс сүзе әйтеп ычкындырабыз. Без аны сизми дә калабыз. Кытайда яшәүче татарлар нужәли инде ана телебезгә шулкадәр мөкиббән, игътибарлы? Тел дигән зур байлыгыбызны чүпләмичә ничек шулай саклап яшиләр? Ә моның сере бик гади икән. «Урысча кыстырырга, без бит урыс телен белмибез, ә ана телебезне дин, гаилә һәм Тукай саклый», – диләр. Алар безнең кебек урыс мохитендә яшәми. Үзара сөйләшкәндә, аралашканда хәтта кытай сүзләрен дә кыстырмый икән. Вәт бит ничек, җәтмә тишек, балык төшә дә кала, диярсең.

Без: «Тел бетә, телебезне бетерәләр...» – дип каравыл кычкырабыз, ә телне куллану даирәсе тараюга үзебез үк юл куябыз. Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың инде ул. Без – урыс мохите җимешләре. Гәрчә татар телен дәүләт статусы дәрәҗәсенә күтәргән закон кабул итсәк тә, ана телебезгә ихтыяҗ тудыра алмадык, закон алдында көчсез икәнлегебезне танып, рәхәтләнеп яши бирәбез. Урысча сөйләшкән кеше үзен акыллырак дип тә хис итә әле. Урысча әйткәндә, сами себя не уважаем. Вот так вот! А вы говорите «нет!» Еще как есть.

НАЧАР БУЛГАН САЕН ЯХШЫРАК

vk.com

Язманың исеме укучыны бераз гаҗәпләндерер, мөгаен. «Начар булган саен яхшырак» дигән девизга мин яшь чакта ук, бөек язучыларның иҗат лабораториясен өйрәнгәндә юлыккан идем. Аның асылы бик гади: шәхси тормышында драма кичерми торып, талант бөек әсәрләр тудыра алмый. Драма никадәр көчлерәк булса, язучы шулкадәр зуррак уңышларга ирешә.

Әлбәттә, тормыш кыенлыклары алдында рухи яктан сынып, сыгылып төшмәгәннәр өчен генә эшли бу кагыйдә. Авырлыклар безне уйланырга мәҗбүр итә, буш хыяллар белән мавыгудан туктата. Аларны югарыга күтәрелә торган баскычның басмасы итеп файдаланучылар әскә менә, каушап, вәсвәсәгә бирелүчеләр түбән тәгәри. Шәһәр сукбайлары арасында белешеп йөрсәң, пьедесталдан егылучыларны тапмый калмассың. Болар – яшьлектә барысы да җай килеп торып югары күтәрелгән һәм, уңышлардан баш әйләнү сәбәпле, упкынга мәтәлгән кешеләр.

«Ватсап»та аралашканда, сабакташларның берсе – тормышта зур югалтулар кичереп, бернигә дә карамыйча уңышлы карьера корган танышым: «Әллә нәрсә генә шунда дөньясы», – дип уфтанып куйды. Бу язма шул сүзләр тәэсирендә әзерләнә. Чынлап та, тормышта шом арта. Җәмгыять бик тыныч ук түгел. Кешеләр һәрбер кабул ителгән законга шикләнеп карый. Җитмәсә, кайбер депутатлар, кирәкмәгән активлык күрсәтеп, чәчләрне үрә торгызырлык канун проектлары әзерләп ята. Депутат Анатолий Вассерманның шәхси кулларындагы бер миллион сумга җиткән акчаны конфискацияләү һәм, шуңа өстәп, ике тапкыр зуррак күләмдә штраф та салу турында канун проекты россиялеләрне шомга салды, мессенджерлар һәм социаль челтәрләрдә зур бәхәсләр уятты, мәсәлән. Инициатива авторына хәтта «Российская газета»да «эрудиция далеко не всегда означает ум» дип бәя бирүчеләр булды. Ул канун проектын искә алуым тикмәгә түгел, чөнки яңалыкны үзем күреп алганчы ук, телефоныма аның хакында хәбәр килеп төште, мөнәсәбәтемне сорадылар. «Кабул ителсә, бу бик начар закон булачак, – дидем мин, – шуның белән яхшы да». Нәрсәсе белән начар, нәрсәсе белән яхшы булачагын дәлилләп тә күрсәттем. Язмамның исеме һәм темасы менә шулай туды.

Моннан нәкъ өч ел элек 2020 елның апрелендә алдагы елларга: «Без бүген барыбыз да тормыш давылында җиңелчә генә сыналабыз. Давыл көче киләчәктә артачак», – дип фараз биргәнмен. «Проблемалар исә сиңа күз яшьләрен җиңгә сөртү өчен түгел, чыныгу һәм көчлерәк булу өчен бирелә. Атаклы инглиз язучысы Оскар Уайльд киңәшен тыңлыйк әйдә: «Мин чын күңелдән сезнең хәсрәт алдында сыгылып төшмәвегезне теләр идем. Безгә авыр сынау булып тоелган нәрсәләр артында чынлыкта яшерен хәер бар», – дигән юллар да язганмын. Фаразларның давыл көчәячәге турындагысы даими тормышка ашып бара, һәм шторм көче торган саен артачак; «көчлерәк булу, авырлыклар артында яшерен хәер» турындагы сүзләрне тормышка ашыру өчен исә тырышырга туры килә. Бүген шулар турында сөйләшүне дәвам иттерик.

Джек Ма дигән чин олигархы бар бит әле. Аны ишетмәгән кеше аздыр. Үзен белмәүчеләр, шиксез, «Алибаба»ны яисә «Алиэкспресс»ны ишеткәннәре бар. Бик зур кыенлыклар, уңышсызлыклар, тормышның зур сынау мәктәбен үткән кеше ул Джек Ма. Кытайда гайкалар бездәгедән катырак та кысылган, анда яшәп, бизнес үстерү, дөньякүләм олигархларның берсенә әверелү – шактый хәвефле эш. Пекин хакимиятләре «Алибаба» хуҗасын берникадәр вакыт элек каты гына кыса башладылар, тормышына һәм бизнесына янаган куркынычны тоеп, егет илдән чыгып качарга мәҗбүр булды. Ил җитәкчелеге белән ара бозылу начар бит инде. Мөһаҗирлектә йөрү миллиардерлар өчен дә бик рәхәт эш түгелдер. Ма чыгып китеп берникадәр вакыт үтүгә, Пекинда аңладылар: ил икътисады өчен Маның мөһаҗирлеге начар, чөнки эшмәкәрләрдә хөкүмәткә ышаныч бетә. Бу – инвестицияләр кими, икътисад хәлсезләнә дигән сүз. Шул сәбәпле Кытайның яңа премьеры Ли Цян Маның илгә кире кайтуын үтенә башлады. Ә бит Кытайның үзәк телевидениесе 2022 елның гыйнварында Ма адресына шундый гаепләүләр яудырган иде: илдә калу яшәү яки үлем мәсьәләсенә әйләнә язды. Югыйсә олигарх хөкүмәт белән хезмәттәшлек юлына баскан иде, бюджетка байтак акча да түләде кебек. Берсе дә булышмады. Илдән китү бердәнбер котылу ысулына әйләнде. Ә хәзер рәсми Пекин аңа җылы мөнәсәбәт күрсәтергә мәҗбүр.

Менә шул Джек Ма безнең кебек фәкыйрьләргә менә мондый характеристика бирә: «Университет профессорына караганда да күбрәк уйлыйлар, сукырга караганда да азрак хәрәкәтләнәләр», – ди. Тормыш проблемаларын чишүнең бердәнбер ысулын күрсәтә: уйга батып йөргәнче, уйлаганыгызны тормышка ашырып карагыз, ди. «Уңышсызлыкка шуның өчен тап буласыз: бөтен тормышыгыз көтеп үтә», – дигән фикер уздыра. Тизрәк хәрәкәт итегез! Маның тормыштагы төп принципларыннан берсе шул. Кул кушырып утыруның депрессиягә батыруын һәркем үзе дә аңлый ала.

Депрессиядән котылуның иң яхшы ысулларыннан берсе – уңай фикер йөртү. Үткән көздә мобилизация стрессы башлангач, без бер язмада Аллаһы Тәгаләнең пәйгамбәр хәдисе аша кителгән бер киңәшен искә төшергән идек: «...Колым минем турыда яхшы уйласа, аңа яхшылык булачак, начар уйласа, аңа шул ирешәчәк». Хәсрәткә бату – Аллаһ турында начар уйлауның бер мисалы ул. Позитив фикер йөртергә күчү өчен, шартларның уңайлануын көтәргә кирәкми, чөнки, бердән, көтсәң, шартлар начараячак кына, икенчедән, уңай фикергә күчүгә, шартлар яхшы якка үзгәрәчәк. Бу котылгысыз, чөнки Аллаһы Тәгаләнең вәгъдәсе бар: «Шөкер итүчеләргә, нигъмәтләремне арттырырмын», – ди («Ибраһим» сүрәсе, 7 нче аять). Тагын бер аятьнең тәфсирен өстик әйдә: «... әгәр шөкер итсәгез, Аллаһ ни өчен сезне газап кылсын...» («Ниса» сүрәсе, 147 нче аять). Игътибар итик: стресс газабыннан котылу өчен, тормыш бик нык авырайганда... шөкер итүгә күчәргә кирәк. Бу формула, бәлки, бик үк аңлашылып бетми торгандыр. «Тормышны күркәм яклары өчен генә түгел, авырлыклары өчен дә хөрмәт итәргә тырышыгыз», – ди бу хакта Иосиф Бродский. «Позитив фикерләү гел яхшылык өмет итеп тору түгел, ә хәзерге моментта син кичергәнне иң яхшысы дип кабул итү», – ди Нико Бауман. Хәлең бик авыр икән, димәк, синең өчен шулай яхшы. Шул авыр хәлеңә шөкер итә алсаң, бу – идеаль вариант. Әгәр анысын ук булдыра алмасаң, хәлең эчендәге уңай нәрсәләрне тап һәм шуларга сөен. Тагын да начаррак хәлдәгеләр барын искә төшер.

Хәлең яхшы булганда, шөкер итәргә онытма. Монысы да мөһим, чөнки кешеләр тормыш сикәлтәсез юлдан барганда, ваемсызланалар, шөкер итүне онышалар, хәтта зарланалар. Хәлне начарайтып чыгарырга туры килә аларны ул вазгыятьтән. Аллаһы Тәгалә сине яратса, ваемсыз яшәтмәс, комфорт зонасыннан чыгарып, уйланырга мәҗбүр итәр, чөнки яраткан колларын авырлыклар белән сыный.

Бүген Россиядә яшәү бик авыр, гайкалар кысылган, хезмәт хаклары түбән, бәяләр югары, медицина хезмәте күрсәтү ташка үлчим дип канәгатьсезлек белдерүчеләргә киңәшем шул: барысын да ташлагыз да чит илгә китегез. Әле чикләр бикләнмәгән, россиялеләрне визасыз кабул итә торган илләр байтак. Чит илдә берничә айга чыдасагыз, туган илдәгедән дә яхшырак тормыш юк икәнлегенә ышанып, кайтып егылачаксыз.

«Тышкы якта үзгәрешләр булсын өчен, эчке якны үзгәртергә кирәк», – ди бу хакта уңышка ирешү методикасы авторларының берсе һәм тормышка карашны үзгәртүнең тормышны үзгәртәчәген әйтә. Авырлыклар безнең тормышка карашны үзгәртә, шуңа күрә «начар булган саен яхшырак» дигән вазгыять туа да тора. Үзгәрә алмасак, без даими авырлыклар эчендә яшәячәкбез, шундый куркыныч бар.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

КӘҖӘМЕ МАЛ ТҮГЕЛ?

Ни өчен бездә кәҗә үрчетү киң таралмаган? Әлеге мал чыннан да киреме? Саба районының Килдебәк авылында булып, Россиянең иң зур кәҗә фермасын күреп, сорауларыбызга җавап алып кайттык.

«Лукоз Саба» кәҗә фермасы – Мари Иленең Сернур бистәсендәге ферманың бер тармагы, филиалы дисәк тә була. Күпләр өчен Сернур үзенең ярты гасырдан артык тарихы булган сыр заводы белән билгеле. Әлеге ферманың кәҗә сөте дә әнә шул заводка китә. Анда исә йомшак сырын да, йогыртын да, каймагын да, кефирын да ясап саталар. Сернур балалар ризыклары ясау белән дан казанган.

Советлар Союзы чорыннан ук исәпләсәк тә, кәҗә фермалары бик булмаган. Бары тик 1980 нче еллар азагында гына берничә кәҗә фермасы оештырып караганнар. Алары да эшләп китә алмаган. Шуңа күрә авыл хуҗалыгында кәҗәчелек – чагыштырмача яңа юнәлеш.

– «Зааненская» токымлы кәҗәләр безнең якларга яраклашкан, – дип таныштырды безне ферманың идарәчесе Рәзил Гарипов. – Шулай да генетик яктан без әле дә чит илләрдән калышабыз. Аны яхшыртыр өчен, тәкәләрне чит илдән алып кайтырга кирәк. Яки килчәктә эмбрион белән эшләргә туры килергә мөмкин. Голландия, Германия, Израильдә кәҗәләрне бик теләп үстерәләр. Әлеге илләрдә кәҗә сөтенә ихтыяҗ зур. Тик безнең халык аны бәяләп бетерми әле. Гәрчә файдасы зур булса да. Бездә хәтта сыерныкын да тиешле дәрәҗәдә бәяләү юк. Шулай да, узган еллар белән чагыштырганда, алга китеш зур. Узган ел үзебездә генә дә сөт күләмен 25 процентка арттырдык. Бу – зур уңыш. Быел да шул күләмне киметмәс өчен тырышабыз.

Чит илләр дигәннән, Рәзил Гариповка төрле илләргә барып, аларның тәҗрибәләрен өйрәнергә насыйп булган.

– Чит илләрдә кәҗә фермалары зур түгел. Иң зур ферманы миңа Голландиядә күрергә туры килде. Анда 10 мең кәҗә асрыйлар иде. Башкаларында 1000, 2000 кәҗә тоталар. Аларда күбесе – савым кәҗәләре. Бәтиләр, тәкәләр аерым фермаларда асрала. Израиль фермаларында кәҗә саннары тагын да азрак. Алар сан артыннан кумыйча, сыйфат өчен эшли, – ди җитәкче.

2011 елда эшли башлаган «Лукоз Саба» фермасында бүген кәҗә санын 3800гә җиткергәннәр. Әлегә шуннан арттырырга уйламыйлар.

– Безнең максат кәҗәләрнең баш санын арттыру түгел. Иң мөһиме: сыйфат кирәк. Сыер нәрсә ашый, кәҗә дә шуның белән туклана, тик алар ризыкка талымлы. Кәҗә – чисталык ярата торган хайван. Ә мал никадәрле чистарак булса, ул шуның кадәрле нәзберегрәк. Авыруларга да тизрәк бирешә. Шуңа күрә елга бер генә тапкыр бәтиләтәбез. Ике тапкыр бәтиләсә, тагын да көчсезләнә, – ди ул.

«Лукоз Саба»да ана кәҗәләрне бала караган кебек тәрбияләсәләр дә, тәкәләргә игътибар алай ук зур түгел. Аларны халыкка да саталар. Әнә беркөнне ике хатын-кыз кәҗә тәкәсе алырга хәтта 4000 чакрым юл узып килгән. Халык арасында сыер асраудан кәҗәгә күчүчеләр булса да, сәбәбе кәҗә фермасында гына түгел, дип саный Рәзил.

– Гомер буе сыер асраган кеше, абзары буш тормасын, кәҗә булса да тотыйк, дигән күзлектән карап ала инде аны. Моңа кадәр мал-туар асрап карамаганына сыеры да, кәҗәсе дә кирәкми, – ди ул.

Зөлфия Хәлиуллина

2018 елда, халыкның сатып алу мөмкинлеге төшә башлагач, сөт бәяләре кимеп киткән булган. Шуннан бирле сөт бәяләре бер дәрәҗәдә тора икән, артмаган да, кимемәгән дә. Бүген исә аның литрын 70 сумнан тапшыралар.

– Мин бу вазыйфага 10 ел элек мал табибы булып эшләгән җирдән күчтем. Безнең халык арасында, кәҗә – мал түгел, дип әйтү бар. Андый шикләр башта үземдә дә булды. Тик хәзер фикеремнән кире кайттым. Кәҗә дә сыер шикелле үк игътибар сорый. Кәҗәчелекнең дә, олы малчылыкның да үз авырлыклары бар. Уңышларын да күрми мөмкин түгел. Ун ел ферма яхшы гына эшләп килә, сөт бирә, продукциясе җитештерелә икән инде, димәк, кәҗәне дә мал исәбенә кертергә вакыт җиткәндер, – ди Рәзил Гарипов.

Кәҗә бик иркә хайван да икән. Фотолар ясарга дип янарына кергәч, кулга алган малкайлар җылы кочакта тәмам «ереп» бетте. Кәҗә мал түгел, дисәләр дә, чиста токымлы савым кәҗәләренең бәясе сыерныкыннан әллә ни ерак китмәгән: 40–50 мең сум. Чит илдән кайтарырга туры килгәндә, 80–90 мең сумга төшәргә мөмкин. Менә шуннан соң, кәҗә мал түгел, дип әйтеп кара син...

Зөһрә САДЫЙКОВА

КӘҖӘ ТУРЫНДА КЫЗЫКЛЫ ФАКТЛАР

1. *Кәҗә сөте составы белән ана сөтенә охшаган. Ул иммунитетны күтәрә, аллергиядән файдасы зур.*
2. *Беренче тапкыр бәтиләгәндә, кәҗә 1–2не китерә, яше арткан саен, бәтиләр саны да арта. Күп дигәндә ул 3–4 бәти китерә.*
3. *Россиядә кәҗә уртача 2,5 литр сөт бирә. Иң күп дигәндә 5–6 литрга җитәргә мөмкин.*
4. *Кәҗә сукмагы, дип юкка гына әйтмәгәннәр. Ул бер юлдан гына барып, кайтканда да шуннан гына кайта.*
5. *Кәҗә – тыныч холыклы, бик акыллы мал. Тик ачуын чыгарсаң, кирелеге дә җитәрлек.*
6. *Кәҗәнең авырлыгы 100 килограммга кадәр җитә.*

САКТА – ТИМЕРЧЫБЫК

Көтү чыгу – бер көйгә генә барган авыл тормышының ритмын үзгәртеп җибәрүче зур вакыйга. Тиздән малкайлар да көтүгә куыла башлаячак. Быел, яз иртә килүгә карамастан, терлекләрен ашыгып чыгарган авыллар юк әле. Елдагыча, май башларын-урталарын көтәләр. Тик елдан-ел көтү тәртибенә үзгәрешләр кертелә, кайдадыр, маллар кимү сәбәпле, көтүе туктый, кайдадыр көтү көтәрлек кешесе калмаган. Шуңа күрә соңгы елларда авылларда электр көтүче аеруча популяр.

Әйтик, Чирмешән районының Туймәт авылы халкы инде күптәннән электрон көтүчегә күчкән. Биредә яшәүче Рамил Кәримов әйтүенчә, ул бик уңайлы, әрсез чүп үләннәргә каршы көрәшү өчен дә менә дигән ысул.

– Терлекләрне көтүгә чирәм күтәрелгәч, май башларында куарга дип уйлап торабыз, – диде ул. – Без хәзер көтү көтәргә кеше эзләп җәфаланмыйбыз. Бар җирдә электр көтүче сакта тора. Аны халык аерым-аерым да, берләшеп тә ала. Мин, мәсәлән, үз малларыма үзем куям. Унар баш терлек асраучылар да үз җайларын үзләре карый. Электр көтүченең урынын алыштырып торабыз. Элек бакча башлары кеше биеклеге чүп үлән була торган иде, хәзер терлекләр торгач, чүп басарга ирек юк. Сарыклар бездә иректә йөри. Алар тәртип бозмый бит, бер урында гына ята. Әлегә бездә көтүгә чыгарлык маллар бар. 70ләп сыер йөри. Тик сөт бәяләре болай торса, алга таба ни буласын әйтеп булмый. Мин зарланмыйм, ничек булса да, барыбер асрыйбыз малны. Сыеры булгач, бозавы да була дигән сүз бит аның.

Азнакай районының Митрәй авылында яшәүче Хәмәдишиннар гаиләсе дә үз терлекләре өчен электр көтүче көйләп куймакчы була.

– Малларны болынга 1 май тирәләрендә куачакбыз, – ди хуҗабикә Рушания Хәмәдишина. – Үзебезнең сарайда дүрт сыер, алты үгез бар. Аларны бер атнада – бер якта, икенче атнада икенче якта көтәбез. Авылда маллар аз калып бара инде. Көтү чыкса да, чиратлап көтәләр. Көтүче яллау дигән күренеш беткәнгә шактый еллар инде. Чөнки авылда көтүгә чыгарлык кеше калмады. Акчасыннан да тормыйбыз. Кешесе булса, рәхәтләнеп бирер идек әле.

Авылларда электр көтүче куеп, аннан табыш алучылар да бар. Мәсәлән, Чүпрәле районының Шланга авылында электр көтүче белән уратып алынган мәйданга куар өчен мал башына айга 600 сум сорыйлар икән.

– Терлекләрне 9 майдан чыгарырга дип сөйләштек. Безнең авылда ике урында электр көтүче тора. Күрше-тирә авылларда да бар җиргә шуны куеп чыктылар. Ул булмаган авылда халык чиратлап чыга. Бездә электр көтүчене бер егет алып куйды. Үзе карый, тәэтәсе җирен төзәтә, тәртиптә, контрольдә тота. Аның өчен без аңа мал башына 600 сум түлибез. Ә икенче як урамда электр көтүчене һәр кеше үзе карап тора, – диде Шәмсия Алимова.

Шулай шул, электр көтүче булса да, малларны барып карап, күзәтеп торырга кирәк. Актаныш районының Киров авылында да, көтүлек җире авылдан читтәрәк урнашканга, чиратлап күзәтеп торалар.

Ярдәмгә электрлы тимерчыбыклар килмәгәннәргә исә терлекләрне үзләренә сакларга туры килә. Чистай районының Исләй авылы халкы да быел, узган еллардагыча, эшне әнә шулай җайламакчы була.

– Безнең авылда көтү ел да 1 май көнне чыга. Гадәттә сыер көтүе ике була. Быел безнең як урамнарда 40–50 баш мал җыела. Без гадәттә үзебез чыгабыз. Булдыра алмаганнар кеше ялларга мәҗбүр. Узган ел 1000–1500 сум түләгәннәр иде. Быелгы бәяләрне әйтеп булмый әле, – диде Гөлнур Фәтхетдинова.

Яңа Чишмә районының Зирекле авылында чиратлап көтәргә ниятлиләр.

– Көтүнең беренче-икенче көннәрендә, маллар өйрәнеп киткәнче, авыррак була. Шуңа күрә өч хуҗалык бергә чыга. Аннан соң ике хуҗалык бара. Яллап чыгарганда, беренче көннәрдә 1500 сум бирәләр дә бераздан 1000 сум түлиләр. Көтүгә 80ләп хайван чыга, – ди авыл халкы.

Мал-туар булсын иде дә, көтүләр куылып торсын иде әле, ди Әгерҗе районының Яңа Бәзәкә авылында яшәүчеләр. Авылда 20ләп сыер булса да, бар халык бергәләп көтүгә куу гадәте бөтенләй беткән. Күпчелек кеше терлеген абзарында тота, бер хуҗалык электр көтүче көйләп куярга уйлый икән.

– Күрше Яңавыл авылында көтүгә чиратлап чыгалар, – диде Фирдәвес Уразманов. – Гадәттә малларны чәчүләр тәмамланган вакытта куалар болынга. Башка елларны 9–15 май тирәләренә туры килә торган иде. Анда 30лап сыер бар. Кызганыч, терлекләрнең баш саны елдан-ел кими. Быел сөт бәясе дә нык төште. Ул да йогынты ясамый калмас. Көтүгә чыгардай кешесе булмаганнар, түләргә мөмкинлек юк дип, малларын сарайда гына тота.

СУ БИРЕГЕЗ!

«ВТ» архивыннан

Авылны уттан саклауда ирекле янгын сүндерүчеләр зур өлеш кертә. 2022 елда алар 840 тапкыр янгын сүндерергә чыккан. Бу – авыллардагы барлык янгыннарның 42 проценты дигән сүз. 110 очракта алар үзләре утны сүндергән. Коры үләнгә капкан утның 106 очрагында алар ярдәмгә ашыккан. Шуларның 36сын үзләре сүндерә алган.

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы Татарстан буенча Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше идарәсе башлыгы Максим Трущин әйтүенчә, яз башыннан коры үләнгә ут кабуның 528 очрагы (әле бу язма әзерләнгән вакытка) теркәлгән. Иң күп янучылар рәтендә – Түбән Кама (106), Әлмәт (430), Тукай (941) районнары.

«ВТ» хәбәрчесе, кара исемлеккә эләккән авылларга шалтыратып, андагы хәлләрне белеште.

Өмет – салым акчасында

Арча районының Наласа авылы җирлеге башлыгы Илфира Шакирова сүзләренә караганда, алар җәйге чорга әзер инде. Ут-күз була калса дип, барысын да хәстәрләп куйганнар. Үзләре әйткәнчә, янмабыз дип утыра торган чак түгел.

– Узган ел бездә көчле янгын булды. Вакытында күреп өлгереп, авылга хәбәр иттеләр. «Игенче» колхозының үз янгын сүндерү машинасы бар. Су тутырылган савыт таккан тракторыбыз ел буе җылы гаражда гына тора. Наласада да, шушы җирлеккә кергән Урта Бирәзә авылында да гидрантларыбыз бар. Күлебездә су бетми, – ди ул. – Гидрантны үзара салым акчасына алып куйган идек. Шулай ук мотопомпалар да алдык. Әмма ул уңайсызрак. Мотопомпа белән су янына якын урнашкан йортларны гына сүндереп була. Башка җиргә йөртү кыен аны. Шуңа күрә бөтен ышаныч – гидрантларда. Авыл халкы белән гел сөйләшеп торам. «Ватсап»тагы авыл төркемнәренә янгын видеолары җибәрәм. Шулай итеп кисәтәм. Сак булырга кушам. Бар да үзебездән тора бит. Әле менә кар бетүгә, берәү көтүлек җирләрен яндырып җибәргән иде. Тиз генә трактор җибәреп, шул урынны сукалаттык. Уяулык бик кирәк.

Ә бит су булмаган авыллар да бар. Сарман районының Иске Ләшәү авылында су алыр өчен инеш-елга юк. Кая барырга? Җирлек башлыгы Илфат Хәбибуллин, авыл уртасында 5 савытка тутырып куелган әзер сулар бар, ди. Бу гына җитәрме соң?

– Авылда трактор бар. Ул-бу булса, аңа тагып, су алып килергә була. Һәр йортның үз скважинасы бар. Авылга бер гидрант кирәк инде. Әмма аны каян алырга? Безгә күбрәк җәй көне кайтып торалар. Кышлыкка 30–40 йортта яшәп калалар. Үзара салым акчасын һәр кешедән 300 сум җыябыз. Аның белән гидрант алып булмый шул. Әмма ничек тә юнәтәсе иде инде, – дип уфтана ул.

Актаныш районының Кыркаентүбә авылы да «сусыз»лар исемлегенә кергән. Алай да, җирлек башлыгы Илшат Кашбразиев сүзләренә караганда, куркыр урын юк.

– Бөтенләй сусыз утырмыйбыз инде. Авылда күл юк. Ә менә 3 чакрым ераклыктагы Кормаш авылында бар ул. 1 чакырымдагы Шәбезбашта су бар. Авылда кечеңә генә кое бар. Аңа да янгын сүндерү машинасы су алырлык итеп торба куйдырдык. Янгын чыга калса, шуннан алабыз. Бездә ут-күзгә сак карыйлар. Халык кисәтелгән. Алар да, авылда гына су юклыгын белгәч, бер чүп тә яндырганнары юк, – ди башлык. – Авылга гидрант кирәк инде. Булачак та ул. Аңа дигән акча махсус оешмага күчкән инде. Узган ел эшләргә өлгерми калдылар. Быел шуны башкарып чыгасыбыз бар.

Ютазы районының Салкын Чишмә авылында да, янгын сүндерәм дисәң, су юк. Дөрес, авыл халкы чишмә суы гына эчә үзе.

– Хуҗалыкның тракторы бар. Күрше Кәрәкәшле авылына гидрант куелган. Суны шуннан алып була. Янгын сүндерү бүлекчәсе бездән 5 чакрымда урнашкан. Аларда бөтен өмет. Ут-күз булса, алар килгәнче, трактор белән утны читкә җибәрмичә торабыз, – ди Кәрәкәшле җирлеге башлыгы Альфред Дәүләтгәрәев.

Югары Ослан районының Мулланур Вахитов авылында да хәлләр хөрти. Янгын сүндерүчеләр монда килгәч, су эзләргә мәҗбүр икән. Элек аларда янгын сүндерү машинасы да булган. Аны күрше авылга биргәннәр. Ярый әле ул машина «исән». Бар бәладән шул коткара икән.

Яңгыр кирәк!

Кукмарада яшәүче Валентина Гарифуллинаның йорты урманга ук терәлеп тора. Шуңа да ул бик куркып яши.

– Ичмаса, бер яңгыр явып үтсә, һавалар алышыныр иде. Кипкән үләннәр чытырдап тора бит. Мин инде мунча да якмыйм. Бакчамдагы коры үләннәрне җыеп алдым, гел күзәтеп кенә торам. Маллар кимеде. Печән чапмыйлар. Уттан Аллаһы Тәгалә үзе сакласын, – ди ул.

КФУның Экология һәм табигатьтән файдалану институты метеорология, климатология һәм экология кафедрасы профессоры Юрий Переведенцев әйтүенчә, бар өмет – Кара һәм Урта диңгез буеннан килүче антициклонда. Аның безнең якка килү-килмәве дә билгесез.

– Яз ике атнага алдан килде. Һава температурасы гадәттәгедән 10 градуска югары тора. Яңгыр булмау бик начар. Җилле көннәр дә туфракны киптерде. Киләсе атна башында яңгыр явар дип көтәбез, – ди ул. – Җиргә дым кирәк. Апрель аенда дымлылык 0 процентны тәшкил итә. Бер атна эчендә генә айлык норманы тутырып булырмы? Май, июнь айларында температура түбән булачак. Эсселәр июльгә кала.

Ник янабыз?

Бу сорау күпләрне борчый. Татарстанның Премьер-министр урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин Татарстанның Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе утырышында, янгын чыгуның 90 процентында кешеләр гаепле, дигән иде. «Үләннең үзеннән-үзе януын тикшерә башлагач, анда да кемнеңдер шешә ташлап калдырганы билгеле була. Шул шешә кызып торып, ут чыга», – диде ул.

Коткаручылар бер төпчек аркасында чыккан янгынны туктатырга күпме хезмәт куелганын яхшы белә. Күп кенә утырышларда чыгыш ясаган район вәкилләре дә, янгынга әзербез, дип хисап тота. Ә аннары яна башлагач, шуны эшлисе бар иде, монысы юк бездә, дип җитәкчеләргә хат юллый икән. Бу хакта Рөстәм Нигъмәтуллин да искә алды. Күңелсез хәлләргә калмас өчен, итәк-җиңнәрне җыярга кушты ул.

– Без, коры үләннән һәм чүп-чардан вакытында чистартуны контрольдә тоту, табигый янгыннарны, үләнгә ут кабуларны, билгесез урыннарда чүп-чар яндыруны, янгыннарны вакытында ачыклауны кисәтү максатыннан, һәр районда профилактика төркемнәре булдырдык. Бүгенге көнгә бу төркемнәр 258 рейд үткәргән. Нәтиҗәдә коры үлән һәм чүп-чар януның 93 очрагы булдырмый калынды, – ди Максим Трущин.

Исегезгә төшерәбез: быел 17 апрельдән 10 майга кадәр республиканың бөтен территориясендә коры үлән һәм чүп-чар яндырырга, шулай ук урман участоклары белән чиктәш торак пунктларда, бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләрендә ачык утта ризык әзерләүгә тулысынча тыю кертелә. Алда – бәйрәмнәр. Күңел никадәр генә табигатькә ашкынса да, ут якмый торсагыз иде! Үзебезгә үзебез зыян салмыйк.

Сүз уңаеннан, шушы көннәрдә Биектау районының Кече Битаман авылы янәшәсендә коры үләнгә ут капкан. Ут урманга таба үрмәли башлаган. Наил Зарипов белән улы Тимерлан, янгын сүндерүчеләр килгәнче, утны туктатып тора алганнар. Шунысы гаҗәп: башкалар аларны читтән күзәтеп, кайсы фотога, кайсы видеога төшереп торган. Ярдәм итәргә ашыгучысы булмаган. Шуннан чыгып та, «Ник янабыз?» дигән сорауга җавап табарга буладыр…

Гөлгенә ШИҺАПОВА

САН

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы Татарстан буенча Баш идарәсенең матбугат үзәге мәгълүматларына караганда, республиканың 1778 торак пунктында янгынга каршы тору өчен су белән тәэмин итү җитәрлек түгел. Шуларның 62сендә урманга ут кабу куркынычы зур. Хәзерге көндә 14 районның янгынга каршы көрәшүче 26 техникасы ремонтта икән. Араларында 2018 елдан бирле төзекләндерелә торганнары бар.

Сусыз авыллар (янгын булса, су алырга бер генә чыганаклары да юк):

✓Кыркаентүбә, Иске Кадермәт, Михайловка (Актаныш районы);
✓Сугышлы, Забугоровка (Бөгелмә районы);
✓Киров исемендәге бистә (Югары Ослан районы);
✓Иске Үби (Чүпрәле районы);
✓Мальцево (Алабуга районы);
✓Каран-Азик (Минзәлә районы);
✓Иске Ләшәү (Сарман районы);
✓Кашка (Тәтеш районы);
✓Саминовка (Чирмешән районы);
✓Салкын Чишмә (Ютазы).

Республикада, суы булса да, кайбер ел фасылларында янгын сүндерүчеләр керә алмаган 32 торак пункт бар. Аларның 5есе – Әлки, 9ы – Биектау, 7се – Менделеевск, 7се – Нурлат, 2се – Питрәч, 1се – Югары Ослан районнарында. Казанның бер бистәсендә дә шундый ук проблема бар.

28 апрельдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Лилия ГЫЙМАЗОВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Сыер асраган өчен субсидия биреләчәкме?

Кызым Алабуга читендәге Иске Алабуга бистәсендә яши. Сыер асрыйлар. Ел саен сыер асраган өчен субсидия алалар иде. Быел бирмибез, дигәннәр. Янәсе, алар авылда түгел, шәһәр җирендә яши. Бу ни дигән сүз икән? Ачыклык кертергә ярдәм итсәгез иде.

Разыя БӘХТИЯРОВА. Тукай районы

Алабуга районының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе Александр Косов:
– Андый сүз булмады. Әлегә без беркемгә дә субсидия бирмәдек. Бу эшкә тотынмадык та әле. Сыер асраган һәркем бу акчаны алачак. Шәһәр җирендә яшәүчесенә дә, авылда көн күрүчесенә дә – барысына да биреләчәк бу субсидия.

Кайда төшерелгән?

Күптән түгел сезнең газетада «Күктау» фильмы турында язма чыккан иде. Ул Сарман районындагы Күктау авылында төшерелдеме икән?

Илмира СӘЛИМҖАНОВА. Казан

Фильмның сценарий авторы, драматург Мансур Гыйлаҗев:
– Әлеге фильм Питрәч районының Кызыл Яшьләр авылында төшерелде.

Чираттагы ялны ничек аласы?

Мин авыл мәктәбендә физкультура һәм тормыш иминлеге дәресләре алып барам. Сәгатьләр саны аз булу сәбәпле, быел бер үк вакытта башка җирдә дә эшли башладым. Төп эш урынымда отпускның озынлыгы – 56 көн, икенче эш урынымда 28 көн генә. Мин чираттагы ялымны ни рәвешле алырмын икән?

РӨСТӘМ Г. Апас

«ВТ» юристы Булат Закиров:
– Әгәр хезмәткәр рәсми рәвештә ике эштә эшли икән, димәк, ул эчке яки тышкы «совместитель» булып тора. Беренче очракта ул бер эш бирүчедә ике хезмәт килешүе буенча эшли, ягъни берьюлы ике вазыйфаны башкара. Икенче очракта төрле эш бирүчеләрдә ике төрле хезмәт килешүе нигезендә эшли. «Совместитель» булган хезмәткәр, төп хезмәткәрләр белән берррәттән, түләүле чираттагы ял алырга хокуклы. Отпуск хезмәткәргә ике вазыйфасы өчен дә бер үк вакытта бирелә. Ике төрле җирдә төрле хезмәт килешүе нигезендә эшләүче хезмәткәр исә үзенең төп эш урынында отпуск графигы нигезендә ялга китә. Ә өстәмә эшендә аңа шул ук чорда гариза нигезендә отпуск бирелергә тиеш (РФ Хезмәт кодексының 286 нчы маддәсе). Төп эш урыныннан алган ял икенче эш урыныннан алганга караганда озаграк була ала. Бу очракта дәвамлыгы буенча аерылып торган көннәр өстәмә эш урыныннан аңа хезмәт хакын саклап калмыйча бирелергә мөмкин (РФ Хезмәт кодексының 286 нчы маддәсе).

Илдар Мөхәммәтҗанов

Дәлил булып торамы?

Дустыма бурычка акча биреп торган идем. Ике айдан кайтарам, дип алган иде. Дүрт ай үтте, әҗәтен һаман кайтарырга җыенмый. Якын кешем булгач, кәгазьләр яздырып, распискалар алып тормаган идем, сүзенә генә ышандым. Хәзер мин бу акчаны ничек кире ала алам икән? «Ватсап»та әҗәт бирү-алу турында язышуыбыз әле дә саклана. Аны дәлил буларак куллана аламмы?

Исемем редакция өчен генә

«ВТ» юристы Булат Закиров:
– Закон нигезендә, 10000 сумга кадәр булган бурычны язма килешү яки расписка кәгазе белән рәсмиләштерү мәҗбүри түгел. Яклар моны үз теләкләре буенча эшләргә хокуклы. Әгәр бер физик зат икенчесенә бурычка 10 мең сумнан артык акча бирсә, килешүнең гади язма формасын үтәү мәҗбүри шарт булып тора (РФ Гражданнар кодексының 808 нче маддәсе). Әгәр дә сез распискасыз гына бурычка 10 мең сумга кадәр акча биргән булсагыз, бу кешегә акча биреп торуыгызны судта шаһитлар ярдәмендә расларга мөмкин. Әгәр дә бурыч суммасы 10 мең сумнан артык булса, шаһитлар күрсәтмәсеннән тыш, акчаны картага яки счетка күчерү турында чеклар, бурычка алучы белән язышу һ.б. да дәлил булачак.

Эшкә чыксам, акча килүдән туктыймы?

Мин әбиебезне тәрбияләгән өчен ай саен компенсация ала идем. Хәзер рәсми рәвештә эшкә урнашырга җыенам. Мин бу компенсациядән баш тартырга тиеш буламмы?

Алсу ВАФИНА. Арча

Россия Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондының Татарстандагы бүлеге:
– Әйе, сез бу хакта безгә 5 көн эчендә хәбәр итәргә тиеш. Караучы кеше эшкә урнашкан очракта компенсация түләве алуга хокукын югалта. Сез, Россия Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондының Татарстандагы бүлегенә гражданнарны карап тәрбияләгән өчен бирелә торган әлеге айлык компенсацияне түләүне туктатуны сорап, гариза язарга тиеш.

Укучы сүзе

«СЫЕР ДА ТӘМЛЕНЕ ЯРАТА» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗЛАР

Бу югары даирә кешеләренең бер дә эшләре юк икән. Гади халыкны һәрвакыт кысып, мыскыл итеп яшәргә генә күнеккәннәр. Сөт бәясе төшеп бара. Инде тир түгеп, көч-хәл белән асраган малны да тикшереп йөрмәсәләр. Көченнән килгән кадәр, күпме асрый ала, шулкадәр асрасын. Ни пычагыма ул чип белән исәпкә алулар. Бигрәк мыскыллап та карыйлар инде авыл кешесен.

Гөлназ ВАДУТОВНА

***

Дөрес әйтәсез, авыл халкына яшәргә ирек бирмиләр. Сөт бәясен төшереп бетерделәр. Хәзер чип куеп, шул хайваннарга салым түләтә башларлар инде. Үзең көч куеп үстергән хайванга бит! Яшьләрне авылга кайтмый, диләр. Хөкүмәттән бернинди ярдәм булмаганда, нигә кайтсын алар анда?

Гөлчирә ХӘЙРЕТДИНОВА

***

Кызык инде безнең халык. Чип куймасыннар өчен нәрсә генә уйлап чыгармыйлар. Һәр малның исәбе булырга тиеш. Шуңа карап, аңа ничә доза вакцина, нинди профилактик чара үткәрергә тиешлеген планлаштырып була. Бик акыллы агайлар, ә нишләп сез 40–50 меңлек машинаны ГАИда исәпкә куюга каршы чыкмыйсыз? Ул машиналар хәзерге заманда сыердан 2–3 тапкыр юньрәк.

Илдус ХАТЫЙПОВ

Фикер

Изге һәм мөбарәк булган рамазан ае тәмамланды. Болдыра алган һәркем, ураза тотып, дога һәм гыйбадәт кылу өчен мәчетләргә җыелды. Әмма безнең авыл халкы изге рамазан аенда мәчетебездә ифтар ашлары үткәрергә, намаз укырга куркып тора. Зәй районының Югары Пәнәче авылында мәчет 1897 елда бай крестьян Габделмәннан хаҗи акчасына төзелеп, 1904 елда эшли башлый. Мәчет ике катлы, диварлары 80 сантиметр калынлыкта таштан һәм тышкы яктан кызыл кирпечтән төзелә. Аның тәрәзәләре шәрык стилендә эшләнә. Тышкы яктан тәрәзәләргә йөзлекләр ясала. Мәчетнең аскы өлешендә ике мич була. Хәзерге вакытта мәчетебез «кирпеч» юнәлешендәге эклектика стилендәге дини архитектура истәлеге булып санала. Мәчет архитектура истәлеге булып саналганлыктан, анда бернинди дә төзү-төзекләндерү эшләрен башкарып булмый. Мәчетнең түшәмендәге штукатурлары кубып төшә, урам ягын да кирпечләр урыннарыннан чыккан, тәрәзә рамнары череп бара. Мәчет эчендә бик салкын, җылытыр өчен рөхсәтсез газ, су үткәрергә ярамый.
Берничә ел инде, мәчеттә салкын булу сәбәпле, дини дәресләрне мәдәният йортында үткәрәләр. Авылыбыз янәннан Чаллы – Әлмәт трассасы уза, шунлыктан бик күп юлчылар мәчеткә намаз укырга дип туктала. Мәчет җылытылмагач, ачылмый.
Авыл күрке – мәчет. Моңа кадәр дә халык яратып йөргән гыйбадәт йортыбыз ярдәм көтә.

Д. ШӘРИФУЛЛИНА

***

Илнең 36 төбәгендә сугыш чоры балаларына нинди ярдәм, ташламалар каралган. Бездә аларның берсе дә юк. Ни эшләп безне шулай кимсетәләр икән? Беркөнне гарьләнеп утырып елыдым.

Казаннан 82 яшьлек ЮЛИЯ апагыз

Киемнәрне сатарга ярыймы?

Ярты ел элек намазга бастым, яулык яптым. Аңа кадәр кигән киемнәремне ни эшләтергә белмим. Аларны сатарга ярыймы икән?

Мәрьям ФӘЙЗУЛЛИНА. Әлмәт

«Иске таш» мәчете имам-хатыйбы Рамил хәзрәт Юныс:
– Әгәр дингә басканчы киелгән киемнәрегез ислам таләпләренә туры килми икән, аларны сатарга яки бүләк итеп бирергә киңәш ителми. Безгә ярамаган әйбер башкаларга да файда китермәс.

Безнең егетме ул?

Гагарин Кубогы өчен көрәштә «Ак барс»ка СКА белән уйнарга туры килсә, тагын да кызыграк булыр иде. Анда бит 4–5 татар егете чыгыш ясый. Ә ЦСКАда берәү генә. Мәскәү командасының һөҗүмчесе Таһир Мингачев Татарстан егете түгелме?

Фәрит ХӘЙРУЛЛИН

Редакциядән:
ЦСКА һөҗүмчесе Таһир Равил улы Мингачевка – 22 яшь. Тумышы белән Самарадан. Спорттагы карьерасын ЦСК ВВС мәктәбендә башлаган. 2019 елда ЦСКА системасына кабул ителә. КХЛдагы тәүге очрашуына ул 2020 елның сентябрендә чыкты. Узган сезонда Гагарин Кубогы иясе булды.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, иң якын, иң кадерле кешесе – әнисе
НУРМӨХӘММӘТОВА Нурдидә Хәмәтнур кызы
вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Рәисе Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызының авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, әнисе
НУРМӨХӘММӘТОВА Нурдидә Хәмәтнур кызы
вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Рәисе Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызының авыр кайгысын уртаклаша.

24 апрель | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30, 01.00 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «КИТӘМ, ДИМӘ» 16+
10.00, 23.00 «ТАИНСТВЕННАЯ СТРАСТЬ». Телесериал 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 16.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». Телесериал 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл» 0+
15.45 «Татар сүзе» 6+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитры) 16+
19.00, 01.35 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00, 01.25 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
00.00 «Каравай». Золотые руки мастеров 6+
00.25 «Соотечественники». Рашид Сюняев. Мы живем в хорошей вселенной 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитры) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитры) 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.10, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Родная земля» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Равил Тумашев турында телеочерк 16+
15.25, 20.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитры) 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
18.20, 21.25 Т. Миңнуллин. «БЕЗ КИТӘБЕЗ, СЕЗ КАЛАСЫЗ». Телефильм. Беренче бүлек 16+
19.30 «Калеб» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
22.35, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
00.40 «Үткәннәр сагындыра» 12+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитры) 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитры) 16+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ». Многосерийный фильм. Новые серии (S) 12+
22.40 «Большая игра» 16+
23.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
00.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
01.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
01.50 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
02.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Футбол не хоккей» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Футбол не хоккей» 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Анна Мельникова, Владимир Ковтун, Алёна Хмельницкая, Илья Шакунов, Сергей Горобченко, Евгений Сидихин, Юрий Батурин, Елена Панова, Зоя Буряк, Елена Цыплакова, Олег Алмазов. «ДОРОГА К СЧАСТЬЮ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Детективный телесериал «ДУЭТ ПО ПРАВУ» 12+
03.55 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова, Андрей Арзяев, Дмитрий Ермак. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 14.20 «Лучшие из лучших» 12+
06.30 «Здоровый образ. Фигурное катание» 12+
07.00, 10.00, 12.50, 14.50, 18.25 Новости
07.05, 21.10, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.30, 02.30 Специальный репортаж 12+
10.25 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
11.25 Смешанные единоборства. UFC. Сергей Павлович против Кёртиса Блэйдса. Трансляция из США 16+
12.55 «Есть тема!» Прямой эфир
14.55 «География спорта. Сочи» 12+
15.25 «Громко». Прямой эфир
16.25 Мини-футбол. Чемпионат России. PARI-Суперлига. 1/4 финала. «Синара» (Екатеринбург) – «Ухта». Прямая трансляция
18.30 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. «Спартак» (Москва) – «Краснодар». Прямая трансляция
21.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Аталанта» – «Рома». Прямая трансляция
00.30 Футбол. Юношеская лига УЕФА. Финал. Трансляция из Швейцарии 0+
03.10 Новости 0+
03.15 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. 1/2 финала. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Динамо» (Москва) 0+

НТВ
04.40 Сериал «ПЛЯЖ. ЖАРКИЙ СЕЗОН» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный детектив «НЕВСКИЙ. РАСПЛАТА ЗА СПРАВЕДЛИВОСТЬ» (S) 16+
22.15, 00.00 Премьера. Максим Дрозд в детективном сериале «ФАЛЬШИВЫЙ ФЛАГ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.55 «Давай разведёмся!» 16+
08.55 «Тест на отцовство» 16+
11.05 «Понять. Простить» 16+
12.10 «Порча». «Цып-цып» 16+
12.40 «Знахарка» 16+
13.15 «Верну любимого» 16+
13.55 «Голоса ушедших душ» 16+
14.30 «ПРОШУ ПОВЕРИТЬ МНЕ НА СЛОВО» 16+
19.00 «КОГДА СПАДЁТ ПЕЛЕНА» 16+
22.05 «Забота о важном» 12+
22.10 «КОГДА СПАДЁТ ПЕЛЕНА» 16+
23.15 «РАЙСКИЙ УГОЛОК» 16+
03.10 «Порча» 16+
03.35 «Знахарка» 16+

ЗВЕЗДА
05.20 «ВНИМАНИЕ, ГОВОРИТ МОСКВА!» Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 00.55 «ЧЕЛОВЕК-АМФИБИЯ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «СЛЕПОЙ». Телесериал. 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «ЦСКА. Спортивный щит родины». Документальный сериал. Премьера 12+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «ЭКИПАЖ МАШИНЫ БОЕВОЙ» 12+
02.30 «Алексей Леонов. Прыжок в космос». Документальный фильм 12+

25 апрель | Сишәмбе

ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 16.30 «КИТӘМ, ДИМӘ». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ТАИНСТВЕННАЯ СТРАСТЬ». Телесериал 12+
11.00 «Азбука долголетия» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». Телесериал 16+
13.00 «Родная земля» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
15.45 «Татар сүзе» 6+
17.30 «Трибуна «Нового Века» 16+
19.00, 00.50 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Соотечественники» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Соотечественники». В. Боков. Не верь словам, не бойся зла 16+
01.15 «Башваткыч» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитры) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Ком сәгате» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.10, 04.15 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Нәсыйхәт» 16+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Әнгам Атнабаев турында телеочерк 16+
15.25, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитры) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.10 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.20, 21.25 Т. Миңнуллин. «БЕЗ КИТӘБЕЗ, СЕЗ КАЛАСЫЗ». Телефильм. Икенче бүлек 16+
22.15, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитры) 16+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ». Многосерийный фильм. Новые серии (S) 12+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
00.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
01.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+
01.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+
02.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Анна Мельникова, Владимир Ковтун, Алёна Хмельницкая, Илья Шакунов, Сергей Горобченко, Евгений Сидихин, Юрий Батурин, Елена Панова, Зоя Буряк, Елена Цыплакова, Олег Алмазов. «ДОРОГА К СЧАСТЬЮ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Детективный телесериал «ДУЭТ ПО ПРАВУ» 12+
03.55 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова, Андрей Арзяев, Дмитрий Ермак. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 14.20 «Лучшие из лучших» 12+
06.30 «География спорта. Сочи» 12+
07.00, 10.00, 12.50, 14.50 Новости
07.05, 15.25, 18.25, 22.00, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
10.05 Специальный репортаж 12+
10.25 Синхронное плавание. Чемпионат России. Прямая трансляция из Казани
12.55 «Есть тема!» Прямой эфир
14.55 «Что по спорту? Владикавказ» 12+
16.25 Мини-футбол. Чемпионат России. PARI-Суперлига. 1/4 финала. «Синара» (Екатеринбург) – «Ухта». Прямая трансляция
18.45 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. Кубок Гагарина. «Ак барс» (Казань) – ЦСКА. Прямая трансляция
22.30 Дартс. Профессиональная лига. Про Тур 2. Прямая трансляция из Москвы
01.15 Американский футбол. Чемпионат России. «Спартанцы» (Москва) – «Северный Легион» (Санкт-Петербург) 0+
03.10 Новости 0+
03.15 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. 1/2 финала. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Динамо» (Москва) 0+

НТВ
04.35 Сериал «ПЛЯЖ. ЖАРКИЙ СЕЗОН» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный детектив «НЕВСКИЙ. РАСПЛАТА ЗА СПРАВЕДЛИВОСТЬ» (S) 16+
22.15, 00.00 Премьера. Детективный сериал «ФАЛЬШИВЫЙ ФЛАГ» (S) 16+
00.55 Детективный сериал «АЛЕКС ЛЮТЫЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.20 «Давай разведёмся!» 16+
09.25 «Тест на отцовство» 16+
10.35 «Забота о важном» 12+
10.40 «Тест на отцовство» 16+
11.40 «Понять. Простить» 16+
12.45 «Порча». «Без рук» 16+
13.15 «Знахарка» 16+
13.50 «Верну любимого» 16+
14.25 «Голоса ушедших душ» 16+
15.00 «ОДНА ЛОЖЬ НА ДВОИХ» 16+
19.00 «НЕОКОНЧЕННАЯ СВАДЬБА» 16+.
22.05 «Забота о важном» 12+
22.10 «НЕОКОНЧЕННАЯ СВАДЬБА» 16+
23.20 «РАЙСКИЙ УГОЛОК» 16+
03.15 «Порча» 16+

ЗВЕЗДА
05.10 «СЛЕПОЙ». Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 01.10 «КРЕПКИЙ ОРЕШЕК» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «СЛЕПОЙ». Телесериал. 5-я – 8-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «ЦСКА. Спортивный щит родины». Документальный сериал. Премьера 12+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «СЛЕД В ОКЕАНЕ» 12+
02.25 «Вальтер Штеннес. Друг против Гитлера». Документальный фильм 12+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга мөһим өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Югары Суды Рәисе урынбасары **Галиәкбәров** Айдар Фатыйх улы, Татарстан Республикасы Югары Суды судьясы **Кормильцев** Андрей Анатольевич; илебез машина төзү тармагын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте җиһазлар һәм инструментлар производствосының кырып киңәйтүче токаре (Зеленодольск шәһәре) **Соловьев** Анатолий Александрович; республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Ямбулат» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы рәисе (Татарстан Республикасы Буа районы) **Фәсхетдинов** Тәлгать Әбделхалик улы; мәгариф системасын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасы «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе урынбасары **Хәлимов** Рамил Мәрван улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Ильин** Владимир Александрович **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы аппаратының җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлеге башлыгы **Вәлиева** Резеда Нәгыйм кызы; җиңел сәнәгатьне үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Бөгелмә тегү фабрикасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Гарипова** Салиха Хәмзә кызы; һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм дәүләт хакимияте органнарында нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Документлар белән тәэмин итү идарәсе эш башкару бүлеге башлыгы **Матвеева** Юлия Олеговна, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы урынбасары **Хәбибуллин** Алмаз Рәшит улы; оборона сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесенең 2 номерлы участогы 23 номерлы цехының контроль-үлчәү приборлары һәм автоматлар буенча слесаре **Пыгина** Александра Ивановна; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, Татарстан Республикасында торак сәясәтен үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесенең торак массивлары белән эшләү бүлеге башлыгы урынбасары **Юрикова** Ольга Ивановна **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башкарма комитетының хәрби-исәпкә алу хезмәте өлкән инспекторы **Богатова** Тамара Владимировна, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башлыгы урынбасары **Заһидуллин** Илшат Минсабир улы, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Илмәт авыл җирлеге башлыгы **Мингалиева** Рәзимә Тимерхан кызы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Оештыру идарәсе Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире **Мотыйгуллина** Гөлшат Әмир кызы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Теләкәй авылы башкарма комитеты секретаре **Рәшитова** Филизә Әнис кызы, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Юхмачы авыл җирлеге башлыгы **Салахов** Рәмис Әнвәр улы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Масловка авыл җирлеге башлыгы **Егоров** Анатолий Иванович, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Олы Елово авыл җирлеге башлыгы **Машанов** Александр Ильич, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Усали авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Нуруллина** Зөләйха Рәис кызы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге башлыгы **Сундурова** Фәридә Абдулла кызы, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Льяшево авыл җирлеге башлыгы **Тихонова** Ирина Алексеевна, Татарстан Республикасы «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесенең бухгалтерлык исәбе һәм хисабы бүлеге башлыгы **Фәхретдинова** Светлана Зиннур кызы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Башкортстан Республикасының Уфа «Нур» дәүләт татар театры дәүләт бюджет мәдәният һәм сәнгать учреждениесе драма артисты **Мөхәммәдиева** Гөлназ Мират кызына, «Созвездие-Йолдызлык» иҗади сәләтле балаларга һәм яшьләргә булышлык күрсәтү республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе артисты **Шнитко** Владимир Николаевичка **«Татарстан Республикасының атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы **Әбләзова** Рамилә Рузалит кызына, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Әхмәтова** Эльмира Самат кызына, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Мәдәниятне үстерү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе балетмейстеры **Ильина** Ольга Александровнага **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасы «Шәһәр яны урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе Иске Казан участок урманчылыгының участок урманчысы **Шәймуллин** Фәнис Данис улына **«Татарстан Республикасының атказанган урманчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ЯЗГЫ КОЯШ АЛДЫЙ

Бит тиресен һәрчак яшь, матур итеп саклыйсы килә. Бигрәк тә яз көне аеруча тәрбиягә мохтаҗ ул. Беренче язгы кояш нурларыннан ничек сакланырга? Кызынганда, каш ясыйм дип күз чыкмасын өчен, нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк?

Табиб-дерматолог, косметолог Дарья ДИЯРОВА язгы чорда тән тиресен тәрбияләү серләрен ачты.

✓ Кыштан язга күчкән мәл – тән тиресе өчен зур сынау чоры. Һава температурасы уйнау аркасында, ул корый, аеруча сизгергә әйләнә. Шуңа күрә яз көне тән, аеруча бит тиресе бозыла. Ул кубалаклана, күпме генә ял итсәң дә, йөздән арыганлык бетми. Шуңа күрә язын тән тиресе аеруча тәрбиягә мохтаҗ.

✓ Яз көне бит тиресен көнгә ике тапкыр чистартып, тоник сөртеп, дымландырып торырга кирәк. Әмма бу чистарткыч чаралар составында зур күләмдә кислота, ретинол һәм С витамины булмаска тиеш. Юкса тәндә пигмент таплары пәйда булачак. Бу чаралар бар да тиренең төренә карап сайланырга тиеш. Тән тиресен чистарткач, кояштан саклый торган крем да сөртеп куярга онытмагыз.

✓ Язгы кояш нурларын түземсезлек белән көтеп алабыз. Беренче карашка, ул бик файдалы кебек. Әмма чынлыкта язгы кояш нурлары җәйгесеннән дә катырак яндыра. Шуңа күрә язын кояшлы көндә кызынырга теләүчеләрнең тән тиресе пешерәгә үк мөмкин. Моннан тыш, ультрашәмәхә нурлар тән тиресен вакытыннан алда картайта, анда җыерчыклар, пигмент таплары пәйда була.

✓ Кояш UVA, UVB һәм UVC дип билгеләнгән нурлар тарата. Беренчесе безне ел әйләнәсе яктырта. UVB нурлар апрель – октябрь аралыгында аеруча көчле тәэсир итә. UVC нурлар исә җир өстенә үк барып җитми. Ультрашәмәхә нурлар ел әйләнәсе актив булгач, кояшка каршы кремны да ел буе сөртергә кирәк. Аны хәтта болытлы көннәрдә дә кулланасы була. Ник дигәндә, ультрашәмәхә нурлар болыт аша да үтә. Аннары кояшка каршы кремнар тире яман шешеннән дә саклый. Шуңа күрә аларны курыкмыйча кулланырга мөмкин.

✓ Акрынлап, кызыну чорына аяк басабыз. Моның да тәртибе бар. Кызынганда, кояш нурлары тирене яндыра. Шул рәвешле, кояш нурлары астында озаграк торган саен, тән тиребез өчен җыерчыклар арту, пигментлар, тире яман шеше килеп чыгу куркынычы арта дигән сүз. Күпләр организмга җитәрлек күләмдә Д витамины керсен өчен дип кызына. Әмма бу – ялгыш фикер. Тән тиресен кояш ашауга, ягъни ул кызарып, каралып китүгә үк, Д витамины эшләнеп чыгудан туктый.

ТУКЛАНДЫРУ БИТЛЕКЛӘРЕ

→ Петрушка биттәге җыерчыклардан һәм пигмент тапларыннан коткара. Бер литр кайнар суга ике аш кашыгы ваклап туралган петрушка салабыз. 10–20 минуттан сөзеп алып, иртән шуның белән битне, муеннарны юабыз. Петрушканы иттарткыч аша чыгарып, шул массаны биткә сылап, ярты сәгать тоту да файдалы. Салкын су белән юып алып, тукландыра торган крем сөртәбез.

→ Берәр аш кашыгы вакланган яшь кычыткан, җылы сөт һәм 1 йомырка сарысы алабыз. Кычытканны сөткә салып, 10 минут тотсы булачак. Йомырка сарысын өстәп болгатабыз да бит, муен тиресенә сөртәбез. 20 минут үткәч, җылы су белән юып төшерәбез.

vk.com

✓ Соңгы арада күз төбендәге тән тиресен патч ярдәмендә дымландыру да популярлашып китте. Алар, дөрестән дә, битнең бу өлешен вакытлыча булса да дымландыра, каралган күз төпләрен агартып җибәрә. Әмма аны чамасын белеп кенә кулланырга кирәк. Патчны атнага ике тапкырдан да ешрак кулланырга киңәш ителми.

✓ Тән тиресе матур һәм сәламәт булсын өчен, иң беренче чиратта, дөрес тукланырга кирәк. Көндәлек рационда ит, йомырка, балык, углеводлар (ярмалар), майлар (житен, үсемлек, авокадо майлары), клетчаткага бай ризыклар (яшелчә, җиләк-җимеш) булырга тиеш. Көн дәвамында чиста су эчәргә дә онытмагыз. Тән тиресен саклау һәм тәрбияләү өчен, баллы, камыр ризыкларыннан, ысланган, тозлы, ачы ризыклардан, каһвә белән газлы эчемлекләрдән баш тарту хәерле. Сөт ризыкларын да чикләргә кирәк.

✓ Организмга тиешле витаминнар да кереп барырга тиеш. Әмма аларны теләсә ничек эчәргә ярамый. Табиб белән киңәшләшеп, махсус анализ ярдәмендә организмга конкрет кайсы витаминның җитмәвен төгәл ачыклагач кына кулланырга кирәк. Витаминнарның да даруханәдә сатылганын гына эчәргә киңәш итәр идем. Ник дигәндә, анда җентекле тикшерену узган, сертификаты булган препаратлар гына сатыла.

КОЯШТАН САКЛЫЙ ТОРГАН КРЕМНАРНЫ НИЧЕК САЙЛАРГА?

• Кояштан саклану өчен SPF кремын сайлаганда, үз тиреңнең тибын һәм кайсы төбәккә барырга планлаштырылуын исәпкә алырга кирәк.

• SPF крем сөрткәннән соң, кояшта гадәттәгедән ун тапкыр озаграк була аласың. Әйтик, «SPF 15» диелгән крем белән ак тәнле кеше кояшта 7 сәгать 30 минут була ала. Ә балаларга SPF дәрәҗәсе 50дән дә ким булмаган крем сөртергә киңәш ителә.

• Кремнар билгеле бер вакытка исәпләнгән. Әйтик, диңгез суында коенганда, кремны һәр ике-өч сәгать саен яңадан сөртергә кирәк. Кояш тиз пешерә торган урыннарга (кул, иңбашы, бит) аны аеруча еш сыларга киңәш ителә.

• SPF кремын, кирәге беткәч, гади су белән генә түгел, ә сабын яки гель белән юып төшерергә киңәш ителә. Аннары кызынганнан соң сөртә торган махсус яки дымландыра торган крем кулланыгыз.

Киңәш-табыш

АЛДАН ЮАСЫ ТҮГЕЛ

Кабыгы чатнаган чи йомырканы ашарга ярамый. Юкса кабыгындагы пычрак һәм микробларның организмга эләгүе бар. Алар температура 70 градустан да югары булганда юкка чыга. Шуңа күрә йомырканы бөтен килеш пешереп ашау хәерле. Роспотребнадзор белгечләре йомырканы һәрчак юып кулланырга киңәш итә. Әмма моны ашарга пешерер алдыннан гына эшләргә кирәк. Алдан юып куйсаң, саклагыч элпәсе юкка чыгып, кабыгындагы микроб һәм бактерияләр йомырканың эченә үк үтеп керергә мөмкин.

Лимон коткара

Лимон кабыгы белән битне сөртсәң, сипкел һәм пигмент тапларыннан да котылырга мөмкин. Әмма бу процедураны ясаган көнне кояш астында йөрергә ярамый. Ник дигәндә, лимон кабыгыннан соң тән тиресе бик сизгергә әйләнә. Кояш нурлары тәэсирендә ул кубалакланырга, каралырга мөмкин. Лимон кабыгын, бераз эчлеге калган килеш, сөялгә куеп тору да файдалы. Аның белән ярылган үкчәләрне дә ышкырга киңәш ителә. Тик бер искәрмә бар: шикәр чире булган кешеләргә лимон кабыгы белән дәваланудан тыелырга кирәк.

Файдалы

Бөресе дә, ылысы да шифалы

Нарат бөресе җыеп куяр чак җитте. Дәвалану өчен нарат бөресен иртә язда, бөреләр ачылганчы җыярга кирәк. Бу вакытта бөреләр кабырчык белән капланган һәм сумала белән беркетелгән була.

▶ Нарат бөресе грипп, салкын тию, йөткерү, бронхит, пневмония, ангина, тонзиллит, фарингит, ларингит, ревматизм, подагра, дерматит, экзема, псориаз, кычыткан бизгәге вакытында кулланыла.

▶ Йөткергәндә, салкын тигәндә нарат бөресеннән ясалган төнәтмәнең файдасы тиячәк. Аны ясау өчен, 1 аш кашыгы нарат бөресенә 2 стакан кайнар су коеп, термоста 1 сәгать төнәтергә, соңыннан сөзеп, көнгә өч тапкыр 1/4 стакан эчәргә кирәк.

▶ Нарат бөресе ваннасы баш авыртканда, нерв киеренкелеге вакытында файдалы. Әмма йөкле һәм бала имезүче хатыннарга нарат бөресе белән дәвалану тыела.

▶ Кан тамырларын чистарту, атеросклероз, бөер авыруларыннан нарат энәсе шифалы. 30 грамм энәне юып, 1,5 стакан су салырга һәм,

өстен ябып, 15 минут эмальле савытта кайнатырга кирәк. Суынгач, шуны сөзеп, өч тапкыр (иртән, төш, кич белән) эчәрлек итеп бүләсе булачак. Теләгән кеше шикәр комы яки бал куша ала.

▶ Нарат бөресе белән ясалган ингаляция сулыш юллары, йөткерү, томау, бронхит, пневмония, тамак авыртканда файдалы. Моның өчен 100 грамм бөрегә 2 литр су салып, 5–10 минут кайнатырга һәм юрганга төренеп, 15 минут шуның парын сулап утырырга кирәк.

Валентина СЕМЕНОВА

РОМАШКА КОТКАРА

Тәрәзә төпләрен помидор, борыч, баклажан ише үсентеләр «яулап алды». Теплицага күчергәнче, матур гына үсеп утырсыннар өчен, аларны дөрес итеп тәрбияләргә кирәк. Юкса төрле авырулар сагалап кына тора. Быел помидор нишләптер әйбәт үсми, яфраклары саргаеп коела, диючеләр күп. «Химия» кулланмыйча гына үсентеләрне ничек сихәтләндерергә?

Күпләрне кызыксындырган шушы сорауга җавапны һәвәскәр бакчачы Әлфинур НӘҖМЕТДИНОВАдан белештек.

– Үсентеләрнең яфраклары саргая яки шәлперәя, куырыла башласа, «химия»дән тыш, үсемлек төнәтмәләре сибәргә мөмкин.

Әйтик, барыбызга да мәгълүм ромашка чәчәкләреннән чәй әзерләргә була. Чыннан да, үсентеләр еш кына куз алдында чирләшкәгә әйләнә. Орлыкларны салкын туфракка чәчүгә яки, суны артык күп сибү сәбәпле, гөмбәчек авырулары барлыкка килүгә бәйле бу. Алар үсентегә туфракның өске катламы астындагы өлешенә һәм тамырларына зыян сала. Үсенте сабагының аскы өлеше каралып, йомшарып кала. Бу «кара аяк» дип атала.

Мондый хәл килеп чыкмасын өчен, үсентеләргә шытып чыгуга ук, ромашка төнәтмәсен бөрку әйбәт. Шулай ук төнәтмәне үсентеләр начар үскәндә дә сибәргә кирәк.

vk.com

Ничек ясарга?

Үсентеләрне дәвалаучы төнәтмә ясауның берниндн дә кыенлыгы юк. Моның өчен кипкән ромашка чәчәкләре (җәен җыеп киптермәгән булсагыз, аптекадан сатып алырга мөмкин) булса, шул җитә. Эмальле кәстрүлгә ярты стакан чәчәк салып, шуңа 2 стакан кайнап торган су коярга кирәк. Өстен калынрак чүпрәк белән каплап, 30 минутлап төнәтергә. Яшькелтем-саргылт төстәге сыекчаны, сөзеп, үсентеләргә бөркергә.

Чәй пакетлары кебек, фильтр-пакетлы ромашкадан (даруханәләрдә сатыла) файдалану бигрәк тә уңайлы. 1 литр суга 10 шундый пакетны салып, ике сәгать тоткач, төнәтмә әзер була. Тәрәзә төпләрендә үсеп утырган чорда үсентеләргә атнага бер тапкыр ромашка чәе (су өстәмәсә) «эчерту» бик әйбәт.

Сүз уңаеннан, ромашка төнәтмәсен, туфракка утыртыр алдыннан, орлыкларны бүрттерү өчен дә кулланырга мөмкин.

Зур үсентеләр фузариос кебек гөмбәчек инфекцияләре белән зарарланган очракта ромашка төнәтмәсе генә ярдәм итә алмый, әлбәттә. Ләкин ул гөмбәчекләрне булдырмау өчен бик кулай.

Дару ромашкасын бакчага да утыртырга мөмкин. 20–25 сантиметр озынлыкта үсеп, яз һәм җәен чәчәк ата торган купьеллык үсемлек бу. Кәбестә янәшәсенә утырту әйбәт. Алар бер-берсенә ярдәм итешеп үсә. Шул ук вакытта бакчага файдалы бөҗәкләр – безелдәвек чебеннәр (журчалка) һәм җайдакларны (наездник) җәлеп итә.

Укучы киңәше

ПЫЧКЫ ЧҮБЕНӘ УТЫРТАМ

Кыяр орлыкларын, тизрәк үссеннәр өчен, туфракка түгел, ә пычкы чүбенә утыртам.

Чәчәр алдыннан, пычкы чүбен кайнар су белән ике тапкыр пешекләп алам. Андагы бактерияләр, гөмбәчекләр һәм зарарлы микроорганизмнарны юкка чыгару өчен кирәк бу. Савытка 4 сантиметр калынлыкта тутырам һәм, бүртсен өчен, өстенә җылы су агызам. Аерым савытка бераз гына пычкы чүбе, су салам. Моңы орлыкларны күмү өчен кирәк. Шуннан теге савытка орлыкларны чәчеп, агач чүбе белән күмәм. Тишелеп чыкканчы, полиэтилен белән каплап тотам. Су сибеп торам. Кыярны, өч яфраклы булуга, туфракка күчереп утыртам.

Фәридә ГАФФАРОВА.
Казан

КИШЕР КУЕ ТИШЕЛМИ

Кишер шытымнары бик куе булмасын өчен, борынгы ысул – кесәл ясап чәчү ысулын кулланам.

Крахмалдан сыек кына кесәл ясыйм да, суынгач, шунда кишер орлыкларын салам (1 стакан кесәлгә 1 чәй кашыгы орлык исәбеннән). Катнашманы чәйнеккә тутырып, буразналарга агызам. Кесәл орлыкларның һәркайсын тышча белән әйләндереп ала, шуңа күрә алар бер-берсенә ябышмый.

Әйбәт, тигез үссен өчен, кишерне сирәкләп торырга кирәк. Май аенда чәчсәм, соңгы тапкыр июнь азагыннан да соңга калмыйча сирәклим. Кайберәүләр аны, һәр кирәк саен түтәлдән йолкып, җәй буе диярлек сирәкли. Ләкин алай аның тамырларына зыян килә, формасы бозыла.

Кишер дымны ярата. Шуңа күрә сирәгрәк, әмма күп итеп су сибәргә кирәк. Һәр көн саен сибә башласаң, яфраклары шаулап утырачак, ә кишере вак, өстәвенә «сакаллы» (бик күп вак тамырлы) булып үсәчәк. Кишер түтәленә тирес кертмәү әйбәт. Юкса яшелчә кәкре-бәкре булып үсәчәк, тәме дә әллә ни булмаячак. Әйбәт туфракка утыртылган кишерне сезонына ике тапкыр ашлау җитә. Беренче тапкыр – тишелеп чыккач, икенче тапкыр – тәүге ашлаганнан соң бер ай узгач. Түтәлне мин түбәндәге ысулларның берсен кулланып ясалган катнашма белән ашлыйм:

- ✓ 10 литр суга 1 аш кашыгы нитрофоска,
- ✓ 10 литр суга 2 стакан агач көле,
- ✓ 10 литр суга 20 грамм калий селитрасы, 15 грамм мочевина һәм 15 грамм «двойной» суперфосфат.

Алсу САБИРОВА.
Тәтеш

Белеп тор!

Тавыкка сода кирәк

Бройлерлар һәм йомырка салучы тавыклар азыгына бераз гына чәй содасы өстәү бик әйбәт: ашкайнату эшчәнлеген яхшырта, тизрәк үсү һәм йомырканы күбрәк салуга ярдәм итә ул.

Соданы суга гына өстәүдән файда юк: кош-корт мондый эчемлекне яратмый. Болай эшләргә: 5 кило катнаш азыкка киптереп төелгән бер уч йомырка кабыгы, 20 грамм чәй содасы (җылы суда эретеп) салырга. Тозсыз пешкән бәрәңге (дөге яки макарон) суы өстәргә. Мондый азык тавык күңеленә бик хуш киләчәк.

Содалы азыкны кош-кортка атнасына бер тапкыр бирү дә җитә. Тавыклар йомырканы аз салган очракта исә, бер-ике ай дәвамында, чиратлаштырып, бер атнада – содалы, икенче атнада содасыз азык ашатырга кирәк.

Тәмле булсын!

Шашлык янына тәмле салат

Николай СЕРГЕЕВ рецепты

Кирәк: *2 бәрәңге, 1 татлы борыч, 1 башлы суган, 2 аш кашыгы консервланган нут, 1 аш кашыгы чистартылмаган үсемлек мае, 2 тырнак сарымсак, 1 чәй кашыгы лимон согы, 1 бәйләм яшел тәмләткеч, тәменчә тоз һәм борыч.*

Бәрәңге, суган һәм татлы борычны юып, һәркайсын 2–3әр өлешкә бүләбез. Татлы борычны орлыкларыннан чистартабыз. Яшелчәнең һәркайсын аерым-аерым фольгага төрәбез. Бәрәңгене – мангалдагы күмер өстендә, суган һәм борычны рәшәткәгә тезеп пешерәбез. 180 градуска җылытылган газ мичендә дә пешерергә мөмкин. Яшелчә 30–40 минут эчендә әзер булачак. Шуннан соң, фольгадан алып, сарымсак (изеп), лимон согы, тоз һәм борыч өстибез. Барысын бергә яхшылап болгатабыз. Яшелчә суынгач, нут һәм яшел тәмләткечләр өстибез.

Салатка үсемлек мае салып болгатабыз һәм табынга куябыз. Җылы килеш тә тәмле булачак ул.

Исеңдә тот!

ЧӘЧНЕ ҮСТЕРӘ

Чәчнең коелуын туктату гына түгел, аның үсүенә этәргеч бирүче маска ясау ысулын беләсезме икән? Бик җиңел: банкага 5–7 дәфнә яфрагы салып, өстенә 300 мл кайнап торган су коябыз. Шуннан төнәтмәгә 3–4 кисәк арыш икмәге йомшагын салабыз. Икмәкнең йомшаруын көтәбез. Катнашманы башка сылап, су коену башлыгы киябез һәм өстеннән сөлге урыйбыз. Ярты сәгать узганнан соң, чәчләрне шампунь белән әйбәтләп юабыз. Масканы атнага ике тапкыр ясыйбыз. Бер айлап вакыт узгач ук, чәчтәге үзгәрешләрне күрергә мөмкин.

САВАБЫ ЕЛ ТУЕНДЫРА

Һиҗри календарь буенча рамазан ае тәмамлану белән шәүвәл ае башлана. Бу айның беренче көнендә мөселманнар Ураза бәйрәмен билгеләп үтә. Бу айның алты көнендә мөселманнарга ураза тотарга киңәш ителә. Хәдисләрдән аңлашылганча, рамазан аенда фарыз уразасын тотып, аннан соң шәүвәл аеның алты көнен дә уразада уздырган кешегә бик күп савап языла.

Шәүвәл ае уразасының үзенчәлекләре турында «Казан нуры» мәчете имам-хатыйбы Алмаз хәзрәт МӨХЛИСОВ белән сөйләштек.

:: Шәүвәл ае мөселманнар өчен нинди әһәмияткә ия? Шәүвәл ае уразасы нидән гыйбарәт?

– Шәүвәл ае – рамазан аеннан соң килә торган ай. Әлеге айның беренче көнендә Ураза гаете билгеләп үтелә. Шәүвәл ае уразасы ул – сөннәт. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Кем исә рамазан аеның фарыз уразасын тотып, аннан соң шәүвәл аенда алты көн ураза тотса, ул ел буе ураза тоткан кебек булыр», – диелә. Билгеле булганча, ислам динендә һәрбер гамәлгә, изгелеккә ун мәртәбә әҗер-савап өстәлә. Ай утыз көннән килеп, шуны унга тапкырласаң, 300 була. Шуңа тагын шәүвәл аенда тоткан алты көн ураза өчен әҗер-савапны өстәсәк, 360 була. Әһиҗри календаренда бер елдагы көн саны 365 түгел, 11–12 көнгә кыскарак. Шуңа күрә шәүвәл аенда ураза тотсак, ул саваплы. Аның хөкеме – сөннәт. Әгәр кеше аны тотмаса, моның өчен гөнаһ язылмый. Шәүвәл аеның беренче көненә туры килгән гает көнендә ураза тоту тыела.

:: Шәүвәл ае уразасын казага калдырып тотарга рөхсәт ителәме?

– Шәүвәл уразасы сөннәт булганга күрә, аны каза кылмыйлар. Фарыз, нәфел уразалары гына каза кылына.

ШӘҮВӘЛ АЕНДА 6 КӨН УРАЗА ТОТУ ФАЗЫЙЛӘТЛӘРЕ

✓**Беренче көн** өчен ул кешенең кырык еллык гөнаһысы ярлыканыр, Аллаһы Тәгалә ул кешегә гамәл дәфтәрен кыямәт көнендә уң кулына бирер. Ул кешегә Аллаһы Тәгалә оҗмах иясләреннән кырык хөллә кидертер. Ул кеше өчен кырык дәрәҗә бирелер.
✓**Икенче көн** ураза тоткан өчен җитмеш хаҗ савабы язылыр.
✓**Өченче көн** ураза тоткан өчен ике йөз шәһит савабы язылыр. Бу кешенең каберен һәр көнне йөз фәрештә зиярәт кылыр, кыямәт көнендә бу кеше өчен изгелекләр язылыр.
✓**Дүртенче көн** өчен Аллаһы Тәгалә бу кешенең дөнья һәм ахирәт хаҗәтләреннән җитмеш хаҗәтен үтәр. Һәр көнне бу кеше өчен җитмеш мең фәрештә мәгъфирәт теләр, ягъни: «Йа Рабби! Бу бәндәнең гөнаһысын ярлыка», – дип дога кылырлар.
✓**Бишенче көн** өчен Аллаһы Тәгалә аның догасын кабул итәр. Ул кешенең кабер газабын күтәрер. Кыямәт көнендә бу кешенең йөзе нурлы булыр.
✓**Алтынчы көн** өчен бу кешегә Аллаһы Тәгалә алтмыш ел ураза савабын язар. Әгәр шушы арада вафат булса, шәһит булып китәр.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Әгәр кешенең калган уразалары булса, башта кайсын тотарга кирәк: казага калган уразаларны тотып, аннары шәүвәл уразасын тотасымы? Әллә киресенчә эшләргә кирәкме? Кешенең ураза тотмаган көннәре бер айга якын булса, аны казага калдырып тоткач, тагын алты көнне тотканчы, шәүвәл ае үтеп китә. Бу очракта казага калдырып тоткан шәүвәл ае уразасы кабул булачакмы?

– Әгәр кеше авыру яки сәфәрдә булу сәбәпле, рамазан аеның кайбер көннәрендә ураза тотмаган икән, аңа каза кылу тиешле, фарыз була. Әгәр ул аны шәүвәл аенда каза кылса, бу ай үтеп китә дә, ул аның савабын алып кала алмый. Галимнәр фикеренчә, бу очракта кеше башта шәүвәл ае уразасын тотып, аннары рамазан аеннан калган фарыз уразасын каза кыла ала. Ләкин, гомумән карасак, шәүвәл ае уразасы бит инде ул сөннәт булып тора. Ә фарызны кайтару тиеш гамәл санала. Без тагын бер ел яши алырбызмы-юкмы, анысын беркем белми. Шуңа күрә кеше, беренче итеп казага калган фарыз уразаларын тотып, Аллаһы Тәгалә каршында бурычларын кайтарып бетереп, аннан соң гына шәүвәл уразасын тотса, хәерлерәк була.

:: Рамазан, шәүвәл ае уразаларыннан тыш, ислам динендә өстәмә уразалар да каралганмы? Шуларны да искә төшереп үтегезче.

– Ислам динендә фарыз һәм сөннәт булган уразалар бар. Аның беренчесе рамазан аенда тотыла. Ай саен өч көн ураза тоту, дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә ураза тоту, зөлхиҗҗә аенда Гарәфә көнендә ураза тоту саваплы, сөннәт санала. Шулай ук Гашура көнендә, ягъни мөхәррәм аеның унынчы көнендә, шәгъбан аеның беренче яртысында ураза тоту да саваплы, нәфел уразасы булып тора. Бу уразалар барысы да – сөннәт. Аларны тотсаң, савабы бик зур була. Әмма тотмасаң, гөнаһы юк. Ислам динендә көнаралаш ураза тоту да саваплы санала.

Гыйбрәтле кыйсса

Хөкем чыгарырга ашыкма

Әтиле-улы поездга утыралар. Улы тәрәзә янындагы урынны сайлый. Поезд кузгалып киткәч, 25 яшьләрдәге бу егет хозурланып һәм бик кызыксынып, агачларны, өйләрне, кырларны күзәтә башлый.

– Әти, кара әле, агачлар әйтерсең безнең арттан чаба! Ә җир әйләнә кебек. Бигрәк кызык, әйеме! – ди.

Әтисе сүзсез генә елмая. Ә янәшәдә утыручы ир белән хатын бер-берсенә карашып ала. Буй җиткән егетнең үзен 4–5 яшьлек бала кебек тотуына аптырый алар. Егет тагын да гаҗәпләнгән тавыш белән:

– Әти, суга кара әле, суда кошлар йөзеп йөри, – ди, үрдәк балаларына күрсәтеп. Бераздан тагын гаҗәпләнүен яшерә алмыйча: «Болытлар бигрәк матур, әйеме, әти. Әйтерсең лә алар, поезд артыннан калмыйк, дип чабалар», – ди.

Беркадәр вакыттан соң җил көчәя, яңгыр сибәли башлый. Тәрәзәне азрак ачып кулын суза, ә инде учына яңгыр тамчылары төшүен күреп исе китә һәм бу юлы да хисләрен яшерә алмыйча атасына дәшә:

– Әти, кара әле, кулыма яңгыр тама, яңгыр! – ди.

Ә әтисе гел сүзсез генә улын күзәтүен дәвам итә. Бу хәлгә исләре китеп утырган ир белән хатын түзмиләр, ата кешегә:

– Ни өчен малаегызны психологка күрсәтеп карамыйсыз, бәлки, берәр дәвасы табылыр иде, – диләр.

Әти кеше тыныч кына:

– Дәваланып кына чыктык әле. Хастаханәдән өйгә кайтып барышыбыз. Сукыр иде ул, әле менә яңа күрә башлады, – дип җавап бирә.

– Шәһәрдә бит ничек: укуга яки эшеңә барып, үз вазыйфаңны башкарып кайтасың да калган вакытны тулысынча үз иркеңдә үткәрәсең. Ә авылда башкачарак. Эштән кайткач та, әле ял итәсең дигән сүз түгел, чөнки өй тирәсендә ел әйләнәсе шөгыль җитәрлек. Хәтта мал-туар, тавык-чебеш асрамаган очракта да җыештыру, төзү һәм төзекләндерү эшләре бетми. Боларның барысы да көч, хезмәт, вакыт таләп итә. Үзеңә дигән вакыт аз кала. Яшьләрнең күбесе нәкъ менә шуңа да шәһәрне өстенрәк күрә инде. Ләкин бу – сәбәпләрнең берсе генә, – ди Илсаф. – Күпмедер дәрәҗәдә яшьләр авылдан үз теләге белән китми, ә китәргә мәҗбүр буладыр. Күпме генә сөйләнсә дә, авыл җирендә шәһәрдәге кебек мөмкинлекләр булмас инде ул. Әйе, өлкәннәрдән: «Авылда да шәһәрчә яшибез инде хәзер: газы, суы кергән, бөтен уңайлыклар да бар», – дигән сүзләр ишетелә. Бернинчә ел элек бу күренешләр зур яңалык кебек тоелгандыр, бәлки, ләкин хәзер түгел. Дәүләттән авыллар өчен төрле программалар, субсидияләр һәм башкасы турында күп һәм еш әйтелә. Әйе, алар бар һәм эшли, ләкин баш күтәрмичә эшләп ятып та булмый бит. Хәзерге вакытта авыл һәм район җиренә яшьләрне җәлеп итү өчен ял итү, күңел ачу урыннары җитми дип уйлыйм. Яшьлек бит ул – энергия ташып торган вакыт. Яшьләргә һәрвакыт нинди дә булса яңалык, кызык кирәк. Әйткәнемчә, монда бер яклы гына фикер йөртеп булмый. Күп нәрсә яшьләрнең үзләреннән дә тора. Эшләгән, оештыра белгән кешегә мөмкинлекләр бик күп. Белмим, бәлки бу замана чиреддер инде: күпләр бит хәзер «алма, пеш, авызга төш» принцибы буенча көн күрә. Ягъни бөтен әйбер әзер булырга тиеш, ә аны булдыруда катнашасылары, хезмәт куясылары килми. Бу безнең өлкәдә дә еш күзәтелә. Берәр тәкъдим белән чыксаң, күпләр хуплап ала, ә шул тәкъдимне чынга ашыруда бик сирәкләре генә катнаша. Тырышкан кеше авылда да матур һәм яхшы тормыш алып бара, – дигән фикердә Баландыш егете.

Балтач патриоты

Динә Йосыпова турында шулай дип әйтергә була. Динәне – Балтачтан, Балтачны Динәдән башка күз алдына да китереп булмыйдыр. Журналист һөнәрен үзләштергән 23 яшьлек әңгәмәдәшебез хәзерге көндә Балтач гомуми белем бирү мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укыта.

– Күңелем гел мәктәпкә тартылган икән, – ди Динә. – Безнең нәселебездә дә – күпчелек укытучы, тәрбияче. Әнием дә заманында Казан мәктәбендә балалар укыткан. Шуңа күрә бу һөнәргә килүем дә табигыйдыр. Узган елның март аенда мәктәпкә эшкә керү турында уйлый башладым. Моңа кадәр районадагы «Хезмәт» газетасында эшләдем. Укытучы дус-ишләрем белән кич сөйләшкәндә дә аларның һөнәренә кызыга идем. Шунысы да бар: башка мәктәптә укытасым килмәде. Күңелем нәкъ үзем белем алган мәктәпкә тартты!

Август аенда мәктәптә эш белешә Динә. «Кая яшеренеп яттың?» – дип, андагы хезмәткәрләр дә яратып шелтәли әле Динәне. Эш табалар яшь белгечкә. Хәер, моңа кадәр дә аны «әйдә, безгә кил, кайт» дип чакырган булалар. Сәгате җиткән, күрәсең. Журналист һөнәре буенча белем алганда рус теле һәм әдәбияты болай да кирәк бит. Шуңа да Балтач кызына квалификация узу җайлы була. «Балаларны бик тә яратам! Эшебездә иң мөһиме дә әнә шул. Ансыз булмый. 5, 6, 8 нче сыйныфларда укытам. Мин – укытучы апа!» – дип горурланып сөйли әңгәмәдәшебез.

Балтач яшьләргә бай, ди Динә. Мәктәптә дә яшь укытучы апа-абыйлар шактый. Гомумән, нинди генә өлкәне алма, яшьләр эшли, яшьләр сата, яшьләр нидер кора икән.

– Башка шәһәргә күченеп китү турында уйлаганым да юк. Мин гаиләмә, якыннарыма, туган ягыма бик бәйле. Егетем дә – кала малае түгел. Ул да Балтачны ярата, – ди Динә. – Балтачта миңа рәхәт. Районыбыз шәһәр шикелле. Бездә барысы да җитеш. Үземнең машинам бар, кирәк икән, Казанга бара алам, кыенлык юк. Шәһәрдә җәйсыз. Мин тынычлык яратам. Шәһәрне исә тынгысыз тормышны үз итүчеләр сайлыйдыр. «Кайда тудың, шунда кирәксең», – диләр бит. Минем очракта да шулайдыр дип уйлыйм.

Мәдәният сагында

– Танышларым арасында авылдан чыгып китеп, шәһәрдә торучылар бик күп. Шәһәрдә хезмәт хакы югары, үсеш мөмкинлекләре күбрәк, диләр. Бу сүзләрдә өлешчә хаклык бар. Үземә исә Казанны Арчага алмаштыру кыен булмады, авыл кызы булуыма да бәйледер бу, – ди Арча Мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе булып эшләүче Ләйлә Хәкимова. – Шәһәр шау-шуына караганда тынычлыкны кулайрак күрәм. Шәһәрдә тормыш тиз ритмда бара сыман, кешеләр бер-берсен күрми, каядыр ашыга. Арчадагы мохит, аның кешеләре миңа бик якын.

Ләйлә сүзләренчә, район-авылларда эшкә урнашу мәсьәләсе генә катлаулырак. Әйтик, ул белеме буенча – журналист. «Арчада белгечлек буенча эш таба алмадым. Шуңа хәзер сәнгать җитәкчесе вазыйфасын башкарам. Аннан, районавылларда үз эшеңне башлау күпкә җиңелрәк. Без, мәсәлән, хуҗалыкта чабышкы атлар асрыйбыз», – диде ул.

Шәфкатьле Исламия

Кайбыч районындагы Олы Урсак авылы кызы Исламия Кәримовага ана сөте белән бергә туган ягына мәхәббәт тә күчкән диярсең. Бала чагыннан ук спорт белән дус булган, атта йөргән, шигърият сөйгән кыз, Казанда медицина буенча белем алып, Олы Урсакка кайтып, эшкә урнашты. Бер генә минут та шәһәр хастаханәләрендә эшләп карамыйча!

– Медицина юлыннан китүемә дәү әнием сәбәпчедер. Дөрес, безнең гаиләдә шәфкать туташлары да, табиблар да юк. Дәү әнием дә – тирә-якта даны таралган пешекче. Ул миңа безнең авылда озак еллар фельдшер булып эшләгән Асия апа Әхмәтҗанованы гел үрнәк итеп куя иде. Асия апа безгә дә еш килгәли иде. Аңа барысы да рәхмәт әйтеп кала, дәү әнием миңа Асия апа үз иткән һөнәрнең нинди дәрәҗәле, җаваплы һәм мәрхәмәтле булуын сөйләрдә, – ди Исламия.

Дәү әнисенең сүзләре кечкенә йөрәгенә таба юлны тиз тапкан, күрәсең. Югса аның да әнисе Кадрия ханым кебек үк укытучы булырлыгы да бар иде бит! «Әни башкарган эшнең авырлыгы гомерлеккә күңелемдә калды. Белем бирүгә караганда дәвалауны күбрәк үз иттем», – ди Исламия.

Медицина көллиятендә укып, диплом алгач, үз теләге белән районга кайта үҗәт кыз. Район хастаханәсенә юл тота. Баш табибтан эш сорый. Тиз арада аны туган авылына фельдшер ярдәмчесе – шәфкать туташы итеп билгелиләр. Олы Урсакка гына түгел, Кече Урсак, Бушанча, Чүкри Алан кебек авылларга да хезмәт күрсәтә шәфкатьле һөнәр иясе. Бәхетен дә туган җирендә таба Исламия. Күптән түгел сөйгәне Илсур белән никах укытып, парлы тормыш юлын башлап җибәргәннәр әнә.

«Авылдан китмәдем дә»

Миңнур Шәмсетдинов – Питрәч районындагы Чыты авылыннан. Ул да – мәдәният сагындагы кеше. 18 ел шул өлкәдә. Авылда яши, гаилә корабыз дигәч, хатыны да авылга кайткан. Хәзер өч балалары бар.

– Авылдан китеп тормадым да мин, – ди ул. – Авылны нәрсә өчен якын итәмме? Мин, авыл өчен файдалы эш башкара алсам, кешеләрне сөендерә алсам иде, дим. Шәһәрдә ул эш белемни дә. Авылда күренә. 500 кеше яши икән, шул 500 кешегә файда китерерлек эш башкарырга була. Чишмә чистартырга, өмә оештырырга, мәсәлән. Үз туган авылыңны ярату – ватанпәрвәрлек. Аны сүз белән генә аңлатырлык түгел.

Авылда калмаучы яшьләрне аңлыйм, ди Миңнур. «Бөтен кеше дә авылда калып та бетә алмый. Эш тә юк инде. Яшь буынга акчалы да, җиңел дә эш кирәк бит. Авылга кеше олыгайгач тартыла. Мин исә яшьтән үк яраттым. Шәһәргә «крутой» булам дип китәләр инде. Эш – сәбәп кенә», – дигән фикердә Миңнур.

Авылны саклау өчен авылда калу кирәк дигән фикердә әңгәмәдәшебез. «Син калсаң, бер кеше кала. Өйләнсәң, кешеләр тагын арта. Балаларың да төпләнеп калса, менә шул инде авылны саклау. Авылда үз эшеңне башлау да моңа йогынты ясый», – ди Миңнур.

Миңнур Шәмсетдинов берничә ел инде мөселманча балалар Сабан туен оештыра. Балаларга чын бәйрәм ясыйлар, шул рәвешле яшь буынга динне дә сеңдерәләр. Май азагы – июнь башында быел да үткәрергә ниятләп тора.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

САН

➤Соңгы 20 елда Татарстан авылларыннан 102 мең кеше киткән. Калага, нигездә, халыкның 18–58 яшьтәге хезмәткә яраклы кешеләре күченә.

➤2020 елгы халык санын алу мәгълүматлары буенча, шәһәрләрдә 3074048 татарстанлы яши, ә авылда – 930761.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ИСКЕ ЯҢАДАН САКЛАМЫЙ

Яз – табигатьтә генә түгел, өйдә дә чистарыну вакыты. Өйләр юарга тотынганчы, кыш буе тузан җыеп торган шкафларны, андагы киштә-киштә кием-салымны да рәтлисе бар. Күлмәк-чалбар өч ай һәм аннан да күбрәк вакыт киелми икән (бу сезонлы киемнәргә кагылмый), димәк, ул сезгә кирәкми һәм аннан котылырга кирәк, ди психологлар. Иске кием-салымны нишләтергә? Киелмәгән туфлине сатып, акча эшләп буламы? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауларга җавап эзләде.

– Өч улыбыз бар, аларга кием сатып алырга өлгер генә, – ди Казанның Салмачы бистәсендә яшәүче Ләйсән Шәрипова. – Хәзер бала-чага бик иркә. Чалбарның тезе әз генә сүтелә башласа да: «Ертыкны кимим», – дип киреләнә. Ямау салу турында сүз дә юк. Өстәвенә, балалар бик тиз үсә. Бер-ике тапкыр кигән киемнәре дә кечерәеп кала. Элек аларны сәүдә үзәкләрендәге чит ил кибетләренә тапшыра идек. Гаиләгә казнасына да азмы-күпме файда: чүпрәк-чапрак тапшырсаң, шул ук кибеттән яңа футболка-күлмәк алганда ташлама бирәләр иде. Хәзер мондый кибетләр калмады. «Авито»га куеп сатам дисәң дә, әллә ни акча эшләп булмаячак. Андагы игъланнар санныннан гына да башың әйләнерлек. Иске киемнәрне кайсын чүпрәк-чапракка дип кискәләп, кайсын бакчага алып чыгып ягарга дип, капчыкларга тутырып куйдым. Әрәм мал инде, тик нишләтәсең?

Рәсми саннарга караганда, илдә ел саен 100–150 миллиард данә кием-салым җитештерелә. Казан кебек зур шәһәрләрдә тәүлегенә 10 тоннага якын чүпрәк-чапракны чүп чиләгенә ташлыйлар, ди белгечләр. Киләчәгебез турында борчылып, Россия вице-премьеры Виктория Абрамченко илдә яшәүчеләргә, мода артыннан куып, ел саен яңа джинсы чалбар сатып алмаска да киңәш итте әнә. Сыйфатына күрә кайбер тукымалар чүплекләрдә 40 елга кадәр таркалмыйча агулы матдәләр таратып ята икән. Бүген кием-салым кибетләрендәге «байлык»ның күпчелеге синтетикадан торуын исәпкә алсаң, уйланырга җирлек бар.

Әйбәт гамәл

Шкафларда шыплап тулган киелми торган киемнәрне нишләтергә? Ташларга кызганыч булган, әле ярарлык киемнәрне хәйрия фондларына бик теләп кабул итәләр. Интернет мәгълүматларына ышансаң, башкалада гына да унбишләп шундый оешма бар.

– «Хорошие руки» хәйрия складында иске кием-салымны бушлай кабул итәбез, – ди үзен Виктория дип таныштырган волонтер. – Моннан тыш, савыт-саба, китаплар, уенчыклар китерергә дә мөмкин. Гомумән, безгә «Нәрсә тапшырырга ярамый?» дигән сорауга җавап бирү җиңелрәк. Ремонтларга кирәк булган аяк киемнәрен алып килүчеләрне генә кире борабыз. Кием-салымны башкаланың «Парк Хаус» сәүдә үзәгендә урнашкан махсус тартмада калдырып китәргә дә мөмкин. Складта теләсә нинди хәлдәге күлмәк-чалбарларны калдырып китә алалар. Без аларны үзебез сортларга аерабыз. Яхшы хәлдәге киемнәрне мохтаҗларга, аз керемле гаиләләргә, янгында зыян күрүчеләргә таратабыз. Приютлар белән эшлибез. Татарстанга Украинадан күчеп кайтучылар

«ВТ» архивыннан

белән элемтәдә торабыз. Алар гына да 2 меңнән артык кеше бит. Гомумән, теләге булган һәркем айга бер тапкыр паспорт белән хәйрия складына килеп, ошаган әйберне алып китәргә мөмкин. Әлеге чикләү бездәге киемнәрне алып сатуны оештырмасыннар, кием-салым, кадерсезләнеп, кабат «барахолка»ларга әләкмәсен өчен кирәк. Элек әнә шундый хәлләр дә күзәтелә иде. Хәйрия складына көненә 50ләп кеше килә. Сезонлы киемнәргә һәм бала киемнәренә ихтыяҗ зур. Кияргә яраксыз һәм кеше алмаганнарын этләр приютларына озатабыз. Анда аларны кирәк-яракка тотып бетерәләр.

Лаеш районындагы «Ихлас» мәчете имамы Мөдәррис хәзрәт Гыйммранов фикеренчә, үзеңнән артык калган киемне кешегә бирүдән куркырга кирәкми.

– Үз мисалымнан чыгып әйтәм, без гаиләдәге киелмәгән киемнәрне Казандагы «Приют человека» хәйрия проектына алып барып тапшырдык. Кешегә биргән кием аша энергетика китә, сине бозарга, сихерләргә мөмкиннәр дип әйтүчеләр бар. Бу мәсьәләдә шуны әйтәсем килә: без динебезгә, Коръәнебезгә таянып яшибез. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримнең «Бәкарә» сүрәсендә: «Әгәр дә мин моны теләмәсәм, беркем беркемгә дә зыян китерә алмый», – дигән. Кеше хәерле ният белән, исраф булмасын, кешегә ярдәм итим дип, кием-салымын башкаларга тапшыра икән, бу бик хәерле. Аллаһы Тәгалә исраф итүчеләрне яратмый. Бер тапкыр да кием тапшырып карамаган кешеләргә дә бозалар бит. Бу мәсьәлә моңа гына бәйле түгел. Үзеңә кирәкмәгән киемне башкаларга тапшыруның беренчи дә начарлыгын күрмим. Аны яхшы ният белән юып-чистартып бирәсең. Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен дип тапшыру – әйбәт гамәл, – ди имам.

12 тонна күлмәк

Лаеш районының Усад бистәсендәге авыр хәлдә калган кешеләргә ярдәм күрсәтүче «Благо Дарим» хәйрия фондында иске-москыны яңадан эшкәртәләр.

– Без теләсә нинди хәлдәге кием-салым кабул итәбез, – ди хәйрия фонды директоры Алсу Шәрифуллина. – Аларны сортларга аерып, дезинфекциялибез һәм өч төргә бүләбез. «Бирка»лы киемнәр сатуга китә. Аннан кергән акча фондны карап торуга тотыла. Яхшы хәлдәге киемнәрне мохтаҗларга таратабыз. Казанда һәм Әлки районының Базарлы Матак авылында ике кибетебез бар. Без Әлки районының социаль яклау бүлеге белән даими элемтәдә торабыз. Безгә мөрәҗәгать итүчеләр ярдәмгә мохтаҗ булуларын, мәсәлән, аз керемле гаилә, инвалид яки ялгыз яшәүче өлкәннәр икәнен, дәлилләп күрсәтергә тиеш. Ягъни чыннан да ярдәм кирәк кешеләр белән эшлибез. Лаеш районындагы төп бинада да товар тапшыру пункты бар. Кием-салым кабул итү тартмалары Казанның зур сәүдә үзәкләре, төзелеш материаллары кибетләрендә урнашкан. Чүпрәк-чапракны өйдән алып китү хезмәте дә гамәлдә. Хәйрия фондлары белән тыгыз элемтәдә торабыз. Әле күптән түгел генә Лисичанскига алты тонна гуманитар ярдәм җибәрдек. Эшкә ярамаган чүпрәк-чапракны яңадан эшкәртәбез. Моның өчен махсус цех бар. Калдык-постык тукымадан күбебезгә идән юу чүпрәге буларак таныш булган йомшак тукыма (ветошь) җитештерәбез. Аңа машина юу, машина ремонтлау хезмәтләрендә ихтыяҗ зур. Татарстанда мондый эш белән шөгыльләнүче зур сәнәгать оешмалары юк. Күрше Чабаксарда, Ивановода, Чиләбедә тукыманы яңадан эшкәртәләр. Үзебез эшкәртә алмаган тукымаларны аларга озатабыз. Кешеләргә ярдәм итеп, экологияне дә кайгыртабыз. Безнең кулдан аена 12 тоннага кадәр кием-салым уза.

Фикер

Илдус САФИУЛЛИН, икътисад белгече:

– Илдә, гомумән дә, тукыманы яңадан эшкәртү сәнәгате зур үсеш алмаган. Иске чүпрәк-чапракның 10 проценты да заводларга китми. Ивановода шундый сәнәгать бар дип беләм. Биредә аена 600–700 тоннага кадәр иске-москыны яңадан эшкәртәләр. Тик экологлар әйтүенчә, полигоннарга елына 175 мең тоннага кадәр кием-салым, чүпрәк-чапрак чыгарыла. Сер түгел, Россиядә тукыманы яңадан эшкәртү белән шөгыльләнүчеләр чималны, нигездә, Европадан алып кайта иде. Чөнки чүпне сортларга аерып утыру бик күп вакыт һәм кул хезмәте таләп итә. Бу – табыш китерә торган бизнес түгел. Шуңа күрә әлеге мәсьәлә күбрәк экологияне кайгыртучыларны борчый да инде.

ИСЕМЕ ТҮГЕЛ, ҖИСЕМЕ

Казанда киелгән киемнәр сатучы кибеткә иске туфли тапшырып, акча эшләргә дә мөмкин. Дөрес, чынын түгел, ә «свалка-сум». Кибет үзе дә гадәти «сэконд-хэнд»лардан аерыла. Башкаланың үзәгендә урнашкан «Свалка» винтаж-маркетында сатылучы «икенче тормыш» алган кием-салым, савыт-саба, көнкүреш техникасы, китап киштәләрен «ВТ» хәбәрчесе дә карап кайтты.

Бирелә элеккеге заманда сервантта гына торган чәчәкле касәләрдән алып «бренд»лы кышкы пәлтәләргә кадәр бар да бар. Сыйфатлы киемнәр бинаның икенче катында урнашкан, ә беренче катның бер яртысында – кием-салым (рәтләр арасында халыкның күп булуы игътибарны җәлеп итте), ә икенче якта – көндәлек тормышта очратырга мөмкин булган әйберләр бар. Шуңа күрәме, күбрәк музейны хәтерләтә ул. Диварга элеккеге ялтыравыклы картиналар эленгән, идәннән түшәмгә кадәр сузылган киштәгә магнитофон кассеталарын тезеп куйганнар. Күн чемодан, элеккеге радиола, «Зингер» тегү машинасы, тәрәзә төбенә сыешкан телефон аппаратларының да нинди генә төре юк. Китап киштәсендә татар тележдәгеләре дә шактый. Муса Җәлил, Һади Такташ җыентыклары бар.

– «Свалка» проекты Мәскәүдә 2015 елдан бирле эшли. Казанда исә социаль әһәмияткә ия булган әлеге экологик бизнесны 2019 елда башлап җибәрдек, – ди кибет директоры Тимур Щербин. – Күреп торасыз, без кием-салымнан алып бизәнү әйберләренә кадәр кабул итәбез. Аларның күбесен хәйрия оешмаларына, приютларга җибәрәбез. Эшкә яраксыз булганнарын яңадан эшкәртүгә озатабыз. Товарларның зур булмаган өлеше исә кибеттә кала, аларны ташламалы бәядән сатып, иске әйберләргә яңа өй табарга ярдәм итәбез. Кием-салым, көнкүреш товарларын курьер хезмәте аша җибәрү, өйдән барып алу хезмәте дә бар. Халыкның төрле катлавына туры килерлек товарлар җыярга тырышабыз. Бездә үсмерләр өчен чагыштырмача арзан кием-салым да, мода сөючеләргә «бренд»лы күлмәк-чалбарлар да бар. Кибеткә тапшырган әйберләр өчен ташламалы купон, ягъни «свалка-сум» бирәбез. Аның ярдәмендә безнең кибеттән 50 процентка кадәр ташлама белән товар сатып алырга мөмкин. Шул рәвешле бирәүләр өчен кирәксезгә әйләнгән чигеп эшләнгән күзлек тартмасының гомерен озайтабыз.

«СВАЛКА»ДАГЫ БӘЯЛӘР
Күлмәк – 1000 сум
Футболка – 500 сум
Хатын-кызлар пәлтәсе – 1200 сум
«Sony» телевизоры – 800 сум
Юка тышлы китап – 50 сум
Калын тышлы китап – 100 сум

«Сэконд-хэнд»лардан аермалы буларак, «Свалка» кибетләре челтәре башка илләрдән кием кайтартмый. Киресенчә, үзебездә булганын мөмкин кадәр чүплеккә атудан саклап калырга тырышалар. Мондый винтаж-маркетлар Санкт-Петербург, Красноярск, Хабаровск шәһәрләрендә дә бар.

– «Свалка» ул – кулланылышта булган товарларны сату урыны гына түгел, бирелә сакчыл куллану, экологик яшәү рәвешенә багышланган чаралар да үткәрәбез. Мәсәлән, иске киемнәрне бизәүгә бәйле мастер-класслар уза. Бу – яңача фикерләргә өйрәнү мәйданы да әле, – ди Тимур Щербин.

ЗӨФӘР МӨХӘММӘТШИН:

«МИЛЛИ СИМВОЛЛАР БЕЛӘН СӘҮДӘ ИТӘРГӘ ЯРАМЫЙ»

Апрель – Тукай ае. Бу айда аның турында истәлекләр барлана, шул ук вакытта шактый гына сораулар да туа. Шагыйрьнең иҗатын, биографиясен бүген кемнәр өйрәнә? Гомумән, тиешле дәрәҗәдә өйрәнелгәнме ул, әллә «ак тап»лар күбрәкме? Тукай турында бүген нинди фактлар һәм нинди уйдырмалар яши? Киләчәктә шагыйрьгә бәйле нинди ачышлар ясалырга мөмкин? Болар хакында филология фәннәре кандидаты, Татарстан сынлы сәнгать музее өлкән фәнни хезмәткәре Зөфәр МӨХӘММӘТШИН белән сөйләштек.



Автор фотосы

:: Еллар узган саен, Тукай бездән ерагая, аның иҗаты, биографиясендәге детальләр онытыла, дигән фикер яши, килешәсезме?

– Теләсә кем, бу дөньядан киткәннән соң, телиме-теләмиме, онытылырга мәҗбүр була. Зур шәхесме ул, кечкенәме, бу – барысына да кагыла торган табигый процесс. Тукайны исә елга бер мәртәбә булса да искә алабыз әле. Туган һәм үлгән көннәре уңаеннан матбугатта мәкаләләр басыла, җыелышлар, очрашулар уздырыла. Шулай булгач, аны бөтенләй онытылган дип әйтеп булмый. Ул башка әдипләр белән чагыштырганда, күпкә бәхетлерәк. Тукай – үз заманында, үз вакытында дөньяга килгән шагыйрь. Үз вакытында шәхесен күрсәтә алган, иҗаты белән танылган. Шигърияте дигәндә, аның гасырлар дәвамында изелеп яшәгән татар халкының җанын, эчке дөньясын, кичерешләрен бирә алган бердәнбер шагыйрь булуын онытмыйк. Әлбәттә, XX гасыр башында күренекле шагыйрьләр шактый. Аларның иҗаты башлыча традицион формада дини-әхлакый мәсьәләләргә багышланган. Тукайда исә, әйткәнемчә, халыкның җаны. Ул шуның белән кыйммәтле һәм бүген шуңа күрә «яши» дә. Мисалга Фатыйх Әмирханны алыйк. Һичшиксез талантлы, әмма Тукай күләгәсендә калган.

> Һәр милләттә йолдыз берәү була. Калганнары аның тирәсендә туплана. Тукай – һичшиксез йолдыз.

:: Йолдыз дигәндә тагын бер шагыйрь – Дәрдмәнд искә төшә. Ни өчен шигърият аның юлыннан үсеп китмәгән, халык аны ни сәбәпле йолдыз итмәгән икән?

– Әлеге сорауга Бакый Урманче архивларына таянып җавап бирсәк, отышлы булыр. Ул, скульптур әсәрләрне иҗат итү өчен, шәхескә кагылышлы материалларны шактый туплаган. Икенчедән, ул үзе дә шигырьләр язган. Иң кызыгы: аның шигырьләрендә Тукай тәэсире түгел, Дәрдмәндкә чагыла. Дәрдмәнд тә бит халык зарын яктырткан, әмма башка шигъри алымнар кулланган. Ул күбрәк Шәрыкка якын. Тукай тәрҗемәләргә шактый урын биргән кебек, Дәрдмәнд тә тәрҗемә белән шөгыльләнгән. Әйтергә кирәк, XX гасыр татар әдәбияты өчен бу – табигый хәл. «Ә ни өчен Тукай – йолдыз?» дигәндә, бер хакыйкатьне истән чыгармыйк: шәхесне күтәрү өчен, аның тирәсендә башка шәхесләрнең тупланиуы кирәк. Аннан соң Тукайның биографиясе дә халыкка якын. Ул халык арасыннан чыккан, халык тәрбиясен алган, тормышның ачысын-төчесен татыган. Һәм менә халык арасыннан чыккан яшь буын аны күтәрә дә инде. Ә XX гасырда хәтта матбугат та ике юнәлештә бара. Өлкән буын традицион юнәлештән тайпылмый, яшьләр радикаль форманы ала. Яңа фикер, яңа алымнарны яшьләр алып килә. Тукай – яшьләр арасында беренче урында. Шулай итеп, яшьләр Тукайны халыкка таныта. Әйткәнемчә, шәхесне шәхес итү өчен, янәшәсендә икенче шәхесләрнең булуы кирәк. Нинди генә даһи булсаң да, янәшәңдә күтәреп алырдай кешеләр булмаса, син беркем түгел. Кызганыч, бу җәһәттән Дәрдмәнд оттыра.

:: Тукай биографиясе яхшы өйрәнелгәнме?

– Өйрәнелгән дип әйтергә була.

:: Европада «йолдыз»ларның биографиясе минутлап язылган...

– Шуңа күрә «...дип әйтергә була» дидем дә инде. Монда кемнедер гаепләп тә булмый. Ник дигәндә, Тукай шәхес буларак бик таркау булган. Шуңа күрә аның архивы да юк. Хәтта ки «аныкы булырга мөмкин» дигән фаразлар да юк. Җавап бик гади: ул аристократ түгел. Аристократларның бу җәһәттән бөтен кәгазьләре тәртиптә. Алар, үзләренең бөеклекләренә ышанып, киләчәкне һәм мирасны уйлап, барысын да җыеп бара. Хәтта гади генә кәгазь кисәге дә саклана. Мәсәлән, Бакый Урманченең архивы нәкъ шулай җыелган. Кәгазь кисәгенәниндидер фикер язган икән, ул аны саклаган. Тукайда алай түгел. Аның турында дуслары, туган-тумачалары сөйләгән, язып калдырган истәлекләргә таянып һәм матбугатта чыккан аңа кагылышлы хәбәрләргә таянып кына ниндидер фаразлар ясап була. Әйтик, менә Уральскида Рәмзия Кәлимулла кызы Шәмсетдинова (аның атасы белән Тукай бер мәдрәсәдә укыган. – **Ред.**) Тукайга кагылышлы күп кенә истәлекләрнең дәреслеккә туры килмәве турында яза. Чыннан да, күп нәрсәләр, кызганыч, халыкның фантазиясенә кайтып кала. Шулай да Тукайның Казан чорын өйрәнелгән дип әйтеп була. Ә менә Уральск (Җаек) чоры караңгы. Тагын шул истәлекләргә таянырга кала. Аның да кайсы дөрес, кайсы уйдырма икәнен әйтү бик авыр. Мин үзем дә Тукайның Уральскида яшәгән еллары турында архивларда ниндидер документлар калмаганмы икән дип кызыксынган идем. Кызганыч, андагы архивлар 1920 елдан гына башлана. Уральск Оренбург губерниясенә кергәнлектән, бу мәсьәләне Оренбург архивларына барып өйрәнергә кирәк. Шагыйрь Уральскига 1895 елда, 9 яшендә китә һәм 1907 елга кадәр шунда яши. Шунысын да искәртик: аның китү вакыты да истәлекләргә таянып кына фаразлана. Фараз бар икән, аны өйрәнергә, дәлилләр эзләргә һәм факт буларак раслап, аны фәнни әйләнешкә кертеп җибәрергә кирәк.

> Кызганыч, бездә өйрәнер кеше юк. Безнең буыннан соң Тукай белән кызыксынучы да булмаска мөмкин. Фәнгә яшьләр килми. Яшерен-батырын түгел, гуманитар юнәлеш бик аяныч хәлдә.

:: Тукайга кагылышлы дөрес булмаган фактлар күпме?

– Бик күп. Казан чоры истәлекләрен генә алсак та, анда берсен берсе кабатлау һәм арттырып җибәрүләр шактый. Документлар булмагач, истәлекләргә кайбер мәгълүматларны әйләнешкә дә кертеп җибәреп булмый. Ләкин, ул истәлекләрне дә инкарь итәргә ярамый. Аларны да яшәтергә кирәк. Бу – үзенә күрә бер идеология. Чөнки әлеге истәлекләр шушы шәхесне биргән халыкка карата бер горурлык хисе тәрбияли. Әмма чама хисен дә югалтырга ярамый. Бер мисал. 2015 елда Әлмәткә барырга туры килде. Шунда Тукайның Тымытыкта булганлыгын әйттеләр. Тукайны бераз белгәнгә күрә, мин шок хәлендә калдым. «Бу фактны каян алдыгыз?» – дип сорагач, алар үзләренең тарихчыларының исемен атадылар. «Ничек барып эләккән ул анда?» дигән сорауга, ни кызганыч, җавап бирә алмадылар. Әлбәттә, бу – фантазия. Фантазиягә таянып иҗат ителгән андый хәбәрләр шактый. Алар буенча, Тукай Актанышта да булган икән. Нишлисең, халыкның шәхесне үзенә якынайтасы килә.

:: Тукай вафат булыр алдыннан нәширләрдән алырга тиешле 500 сум акчасын 2 сәләтле баланы рус уку йортларында белем алыр өчен тотарга васыять итә. Бу васыять үтәлдеме икән?

– Тукай вафатыннан соң, ел саен алдынгы шәкертләргә стипендияләр билгеләнгәнлеге мәгълүм. Казанда гына түгел, Петербург, Уральск шәһәрендә дә бу җәһәттән махсус фондлар оештырыла. Һәм стипендияләрнең тапшырылганлыгы газеталарда күрсәтелеп барыла. Ул елларда Тукай образы шактый кулланыла, аның исеменнәге сабын, конфетлар да чыгарыла башлый.

:: Тукайга кагылышлы тагын нинди табышлар бар?

– Соңгы елларда мин Бакый Урманче архивын өйрәнәм. Анда Тукайга кагылышлы кульязмалар да бар. Әйтик, Нәҗия Әхмәрова *(Нәҗия Әхмәрова – табиб, Сәмаркандта яшәгән. Аның әтисе Габдрахман Әхмәров (1869–1933) Троицк баенда доверенный булган. –* ***Редакция искәрмәсе.****)* Тукайның Троицкига баруы турында тәфсилле истәлек язып калдырган булган. Урманчеда әлеге истәлекнең оригиналы саклана, аңа кадәр бу истәлекне галим Ибраһим Нуруллин, русчадан тәрҗемә итеп, китабына керткән иде. Мәгълүм булганча, шагыйрьне Троицкига кымыз белән дәваланырга алып баралар. Әлеге истәлектә автор шагыйрьне ничек каршы алулары, андагы сөйләшүләр турында җентекләп яза. Хәтта кемнең кайда утыруы турында сызым да бирә. Әлеге истәлек Үзбәкстанның атаклы рәссамы Чыңгыз Әхмәровта сакланган һәм ахырдан ул аны Бакый Урманчега тапшырып калдырган. Анда 1912 елның җәендә Тукайның инде хәлсез булуы сурәтләнә. Кызлар көймәдә йөрергә чакыргач, шагыйрь: «Минем, кызлар, тауларга менеп төшәргә хәлем юк шул», – дип җавап бирә. Әлеге истәлектә Тукай сурәтенең чынлыкка туры килмәве турында да сүз бар. Нәҗибәнең апасы Сара аңа: «Сез үзегезнең рәсемегезгә бер дә охшамагансыз», – дип әйтә. Моңа әтиләре дә кушылып китә. Китап тышлыкларындагы башына түбәтәй, муенына чуар галстук таккан симез генә яшь егет турында сүз чыккач, Тукай: «Ул рәсемдә мин түгел», – дип җавап бирә. «Минем шигырьләремә мәхәббәт булсын өчен, мине авыру күрсәткән рәсемнәрдән ваз кичеп, китап басучылар башка бер кешенең рәсемен Габдулла Тукай рәсеме дип халыкка тараткканнар», – ди. Нәҗия Әхмәрова: «Тукайның тышкы күренеше Клячкин хастаханәсендә ике кулын баш астына куеп яткан сурәтенә бик охшаган иде», – дип язып калдыра. Җәмгыятьтә кешенең кыяфәтенә карап бәя бирү бар. Күрәсең, Тукай да шул хәлгә тарый. Драматург Галиәсгар Камал истәлекләрдә дә бит аның хакында «Солидный гәүдәле Тукай турында исәпләп йөргәнгә, миңа аның бу сүзе бик начар тәэсир итте. Ирексездән, гарәпнең Мөгайди турында ишетүең аны күрүеңнән хәерлерәк, дигән мәкале уемнан узып китте», – дип язып калдыра. Нәширләр, мөгаен, шуңа шундый хәйләкәр адымга баргандыр. Сорауга йомгак ясап, шуны әйтәсе килә: Тукай турында яңалык әйтәсең килсә,

Шигърият

***

Син дә бөек идең ул мизгелдә,
һәйкәл иңсәсендә торганда.
Ә ул төнне бездән бәхетлерәк
тагын кем булды икән дөньяда?

Казан күге – тоташ күбәләк кар,
урамнары тыныч, тын иде!
Кушылулар хыял гына булса,
сөешүләр безнең чын иде.

Күз алдында бөтен торышларың,
күлләрен, елмаюларың...
Бәхет өчен туган хатын-кызның
теләкләрен тойдым мин барын.

Син дә бөек идең ул мизгелдә
гади кеше, шат бер җан булып.
Мин дә әзер идем бөтерелергә
керфегеңдә эрер кар булып.

Кая ашыктык без?
Ник ул төнне озынайтмадык?
Бәхеткәме тиз кул болгадык?
Тукай һәйкәленең итәгендә
ник соң бик аз янды ал яулык?..

Равил ФӘЙЗУЛЛИН

ТУКАЙ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

Ниләр уйлыйсың икән син, Тукай? –
Безнең өчен сызланасыңмы?
Безнең белән горурланасыңмы?
Әллә безне кызганасыңмы?

Ә без һаман синнән калган татар –
Үзгәрмәгәнбездер тамчы да.
Үзгәрмәбездер дә... Хәзер инде
Ярдәм итмәс синең камчы да!

Үз көнебезне без күрер-күрмәс.
Телебезне дә яклар-якламас.
Без һаман шул үләр-үлмәс инде,
Без һаман шул йоклар-йокламас...

Мәскәү абзыебыз әле һаман
Якабыздан тоткан ныгытып...
Үзебезнең татар иканне дә
Җибәрәбез кайчак онытып.

Кыскан саен кычкырырга кирәк!..
Кычкырмыйбыз – тамак карлыккан.
Без дәшмәскә өйрәнгәнбез инде...
Татарлыктандыр ул, тарлыктан.

Йодырыкларыбыз төйнәлсә дә,
Коерыкларыбыз кысылган.
Әйтерсең лә, койрык кысарга да
Кемдер тарафыннан кушылган.

Мактанырга булдырабыз! Имеш,
Заманында дөнья тотканбыз.
Тотканбыздыр... Ләкин ни өчендер
Телебезне генә йотканбыз.

Телсез дә бит елап-көлеп була,
Утырып була көйләр көйләшеп.
Телсез татар ул – иң әйбәт татар,
Аның белән була сөйләшеп.

Телсез татар – иң абруйлы татар!
Телсезләрне була тыңлатып.
Без – сүзсез дә аңлый торган халык...
Нәрсә торам әле аңлатып?!

Безнең хәлләр шушындыйрак инде.
Кайтып керсәң әгәр тегеннән,
Язар идең, Тукай, акылыңнан,
Язар идең туган телеңнән.

Язар идең телдән, киек кошлар
Мәхрүм булган кебек канаттан...
Бу хәлләрне күрсәң, оятыңнан
Үләр идең, Тукай, кабаттан.

Син булса да әйт сүзеңне, Тукай,
Татар теле әле тереме?
Юк, кирәкми, телсезләргә, зинһар,
Әрәм итмә газиз телеңне...

Ни дисәң дә, без шул татар инде,
Нинди генә хисләр кичермә!..
Кичер безне. Тукай, кичералсаң,
Кичер безне...
Хәер, кичермә!

Роберт МИҢНУЛЛИН

архивларны кабаттан өйрәнергә кирәк. Тормышында ачыкланмаган нәрсәләр шактый. Тагын шунысы бар: мөстәкыйль дәүләтең булмагач, нәрсә эшләсәң дә, эшне ахырына чаклы җиткереп булмый.

:: «Шагыйрь мәхәббәте» дигән четерекле тема бар. 26 ел яшәп, нәсел калдыра алмаган кешенең мәхәббәте булу ихтималларын дөньяга чыгару дөресме?

– Шагыйрьнең мәхәббәте истәлекләрдә генә түгел, шигырьләрендә дә чагылган. Мин моны тыелган тема булырга тиеш дип әйтмәс идем. Аңа табынучылар күп булган. Әлбәттә, бу темага нинди максат белән алынасың бит әле. Әгәр шагыйрьне күтәрә икән, яшәсен ул тема да. Әдәбиятка кергән икән, Зәйтүнәгә булган мәхәббәте дә яшәргә хаклы. Ә башкалар турында язганда, уйланырга, бик куертмаска кирәк. Бу җәһәттән дә сәяси якны уйларга кирәк, минемчә.

:: Соңгы елларда Тукайның күп кенә әсәрләре үзенеке булмаган, дигән фикерләр ишетелгәли башлады.

– Баштан ук искәрткәнемчә, XX гасыр башында татар әдәбиятында тәрҗемәләр белән мавыгу табигый. Алар бәрабәренә яңа алымнар барлыкка килә, гомумән, яңа сулыш килеп керә. Тукай гына түгел, башка бик күп иҗат әһелләре рус классикларын, кайсылары шәрык әдәбияты вәкилләрен тәрҗемә иткән. Тукайның тәрҗемәләренә килсәң, аларны бит тәрҗемә дип әйтергә дә тел бармый! Алар шаккаткыч! Аларда – Тукайның эчке дөньясы. Пушкин, Кольцов, Лермонтов, Майков әсәрләре – ләкин Тукай күзаллавы, Тукай күңеле. Чын талант хезмәте. Ә бит чынлап карасаң, Пушкин иҗаты да 70 процент тәрҗемәләрдән тора, Лермонтовныкы да, Тютчевныкы да... Ул кайсы әдәбиятны алсак та шулай. Шуңа күрә дәверенә карап, Европа – Көнчыгыштан, ә Көнчыгыш үз вакытында Европадан тәрҗемә иткән.

> Бездә хәзер шундый кагыйдә: нәрсә беләбез, шуны тизрәк гавамга тарату җаен карыйбыз. Әлбәттә, бу ниндидер танылу, хәзерге тел белән әйтсәк, «просмотр»лар җыюга китерәдер. Әмма символик образлар белән алай шаярырга ярамый. Өч шәхес: Сөембикә, Тукай, Җәлилгә кагылырга ярамый. Сөембикә – милли азатлык, Тукай – милли фаҗига, Җәлил – татар халкының милли патриотик символы. Алар белән сәүдә итәргә ярамый. Дәүләтең булса, бәхәсле моментларны чыгарырга була әле, дәүләтең юк икән, кагылма. Дошманыңа җим бирмә.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык өченче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ:**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кырык өченче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. 2022 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисап.
3. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 397-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
4. «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм Татарстан Республикасы Экология кодексының 2 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 409-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
5. «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 417-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының профессиональ даими нигездә эшләүче депутатлары саны турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 418-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 414-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 416-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 33 статьясына үзгәреш кертү хакында» 413-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
10. «Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 415-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
11. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында.
12. «2022 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында» Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы доклады.
13. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының 2019 елның сентябреннән 2023 елның апреленә кадәрге эш чоры өчен хисабы.
14. «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» Федераль законның 3 һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 310910-8 номерлы федераль закон проекты турында (конгресс-күргәзмә эшчәнлегенең хокукый нигезләрен беркетү өлешендә).
15. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 306906-8 номерлы федераль закон проекты хакында (экскурсоводлар (гидлар), тәрҗемәче гидлар һәм (яисә) озатучы инструкторлар эшчәнлегенә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметын билгеләү өлешендә).
16. «Россия Федерациясе Торак кодексының 199 статьясына үзгәреш кертү турында» 321568-8 номерлы федераль закон проекты хакында (күпфатирлы йортлар белән даими идарә итү өлешендә).
17. «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 304096-8 номерлы федераль закон проекты хакында (күпфатирлы йортта гомуми мөлкәттән файдалану өлешендә).
18. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 322234-8 номерлы федераль закон проекты хакында (торак пунктлар чикләрен һәм территориаль зоналар чикләрен билгеләүгә бәйле мәсьәләләрне җайга салу максатларында).
19. Күпфатирлы йортлардагы урыннар һәм торак йортлар милекчеләренә һәм алардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Мурманск өлкә Думасы мөрәҗәгате хакында.
20. «Хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 295373-8 номерлы федераль закон проекты хакында (хайваннарны яклаучылар эшчәнлеген җайга салу өлешендә).
21. «Россия Федерациясендә тынлыкны һәм гражданнар тынычлыгын саклау турында» 299053-8 номерлы федераль закон проекты хакында.
22. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 258760-8 номерлы федераль закон проекты турында (хәрби хезмәткә мобилизация буенча чакырылган затларның һәм махсус хәрби операциядә катнашучы затларның балаларының белем алуга аерым хокуклары хакында).
23. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә «Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә ирекле икътисадый зона турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә үзгәрешләр кертү хакында» 326734-8 номерлы федераль закон проекты турында.
24. «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 325724-8 номерлы федераль закон проекты турында (коррупциягә каршы көрәш хакындагы законнарны камилләштерү өлешендә).
25. «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 28 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 311094-8 номерлы федераль закон проекты турында (муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре эшчәнлеген туктату өлешендә).
26. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 310814-8 номерлы федераль закон проекты турында (түләүле автомобиль юллары буенча йөргән өчен түләүне кертү бурычын үтәмәгән өчен җаваплылыкны төгәлләштерү өлешендә).
27. «Ихтыярый янгыннан саклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 321818-8 номерлы федераль закон проекты турында (янгын куркынычсызлыгы системасының нәтиҗәлелеген арттыру өлешендә).
28. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 325715-8 номерлы федераль закон проекты турында (наркотикларның законсыз әйләнешен, аларны куллануны пропагандалаган өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә).
29. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе вазыйфаларын башкаручы М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре, 2023 елның 20 апреле
№ 1931-VI ДС

Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары итеп вәкаләтләр чоры чикләнмәгән вакытка түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Зәй суд районы буенча:

1 нче суд участогына – Сөләйманов Айдар Мансур улын;

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Мәскәү суд районы буенча:

3 нче суд участогына – Әхмәди Камил Данир улын;

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Идел буе суд районы буенча:

10 нчы суд участогына – Грицков Евгений Вячеславовичны;

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Совет суд районы буенча:

4 нче суд участогына – Анисимов Роман Олеговичны.

2. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә сайланган Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының вәкаләтләр чоры алдагы вәкаләтләр чоры тәмамланган көннән башлана.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе вазыйфаларын башкаручы М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре, 2023 елның 20 апреле
№ 1932-VI ДС

КОТЛЫЙБЫЗ!

22 апрельдә Чүпрәле муниципаль районы башлыгы Марат Ринат улы ГАФАРОВның туган көне.

Аның безнең районга эшкә килүенә февраль аенда биш ел тулды. Шушы биш ел эчендә район җирлегендә бик күп социаль объектлар сафка басты, капиталь төзекләндерү үткәрелде. Халыкны эчәргә яраклы сыйфатлы су белән тәэмин итү максатыннан 2018–2022 еллар дәвамында 229 чакрымга якын сүүткәргеч яңа торбалар салынды. Башкарылган эшләр нәтиҗәсендә 41 авылга сыйфатлы су килде. Иске Чүпрәле авылында Абдулхак Алимов чишмәсе тергезелде. Гомумән, безнең районда чишмәләргә, аларны төзекләндерүгә соңгы елларда игътибар нык артты. Хәзерге вакытта район халкының 78 проценты чишмә суы эчә. Кыш айларында социаль-мәдәни объектларда тиешле җылылык тоту өчен зур егәрлекле алты казан урнаштырылды. Юкка гына юлларны «Тормыш артериясе» дип атамыйлар. Шуңа да региональ, муниципаль һәм җирле әһәмияттәге юллар төзелде һәм төзекләндерелде. Бар көчен, тәҗрибәсен һәм һөнәри осталыгын туплап, Чүпрәле районы халкының яшәү рәвешен яхшырту максатында намус белән шулай хезмәт итүе өчен без Марат Ринат улын ихлас күңелдән хөрмәт итәбез.

Хөрмәтле Марат Ринат улы! Сезне ихластан күркәм бәйрәмегез белән тәбрик итәбез, корычтай нык сәламәтлек, гаилә иминлеге телибез, авыр һәм җаваплы хезмәтегездә Ходай бары тик уңышлар гына насыйп итсен!

Чүпрәле районы халкы исеменнән,
хезмәт ветераны, совет армиясе һәм
Эчке эшләр министрлыгының
отставкадагы офицеры
Абдулхарис АЛИМОВ

КАТНАШ АЗЫК, АШЛЫК

ФИНИШ БРОЙЛЕРЫ өчен

(26 көнлек һәм аннан зуррак бройлерлар өчен)

КАТНАШ АЗЫК

Глазов һәм Богданович шәһәрләре заводларында җитештерелгән терлек азыгын (бройлерлар, йомырка салучы тавыклар, бытбылдыклар, йорт куяннары, мөгезле эре терлек, күркәләр өчен), шулай ук аертылмаган сөтне алыштыручы ризык, мөгезле эре терлек өчен тоз h.б. сайлап алу мөмкинлеге зур.

Казан, Техническая урамы, 15. **тел.: +792-704-99-706**

Чаллы, Магистральная урамы, 1а/1. **тел.: +792-767-27-366**

** сыер рәсеме төшерелгән сары баннерны эзләгез!*

Безнең сайт: agroline1.ru

реклама

Газетаның киләсе саны 25 апрельдә чыга.

Беләсең килсә...

1. Ленинград өлкәсенең башкаласы?
а) Санкт-Петербург;
б) Выборг;
в) Гатчина.

2. Менделеев таблицасы кайсы элемент белән башланып китә?
а) кислород;
б) водород;
в) азот.

3. «Цугцванг» төшенчәсе шахматта нәрсәне аңлата?
а) алдагы һәр йөреш уңышлы;
б) алдагы һәр йөреш уңышсыз;
в) башка йөреш калмады.

4. Композитор Сара Садыйкованың кызы – ...
а) Галия Кайбицкая;
б) Әлфия Айдарская;
в) Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская.

Җаваплар: 1.в); 2.б); 3.б); 4.б).

Сканворд җаваплары

Горизонталь: бар, пәлтә, йом, Айфара, әзи, армия, Бариева, Слуцкер, артыш, Ра, бикле, ау, мөкатдәс, бие, Иделия, Кирам, ДНС, ара, ТТ, яна, Гани, чи, суган, астыртын, Кили, КамАЗ, бәя, Азалия, ашыкма, как, Вена, каравыл.

Вертикаль: сарык, Кариб, ки, агым, битлек, Илназ, Аппакова, ир, ис, ак, арадаш, Шаман, Әлифба, туем, чыбык, тирәк, вак, Бәйрәм, Шмидт, Тямаев, оазис, өян, сы, нык, Рим, иялек, сауна, сал, ацетон, ака, Янил, керәшен, Ли, рас, Азия.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 14278 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 257

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Вәклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+